# ДУЛКЫН ЭЧЕНДӘ

*Биш пәрдәлек пьеса*

Большевик җәһәннәменнән котылып чыгып, Аурупада бераз киң сулыш алгач та беренче язылган бу әсәрем илемездә меңнәрчә булып үткән вакыйгалардан алынган авыр тәэссоратларның җимешедер. Күптән үк басылып, киң укучыларымызны таныштыру, хосусән, мөһаҗәрәттә үсеп җитә торган яшь буынымызны туган илендәге кардәшләре, туганнарының башыннан үткәнен күз алдында җанландыру бик кирәк булса да, мәгаттәәссеф, матди кысынкылык аркасында бу вазыйфаны вакытында үти алмаган идек. Финляндиянең Тампере милләтчеләре безнең бу милли вазыйфамызны үтәргә имкян биргәнгә, һәммәсенә дә зур рәхмәтләремне укып, укучыларга «Дулкын эчендә»не тәкъдим итәм. Бу китапның сатылышыннан килгән акчаларны икенче әдәби әсәрләремнең басылуына гына тәхсыйс итәм.

Варшау, 1937 ел.

Уйнаучылар:

Разыя — яшь тол хатын.
Бану — аның кызы, мәктәп шәкерте. Гимназиядә укый.
Хәйрулла — урта сәүдәгәр.
Кәримә абызтай — күрше карчыгы, азрак яучы.
Бәкер — Кырым татары, Бануның кияве.
Шәүкәт — әсир төрек малай, 9—10 яшьлек.
Фәритбәк — төрек забыты, Шәүкәтнең атасы.
Фатих — Хәйрулланың угылы, унлык малай.
Шакирә — Хәйрулланың кызы, унберлек кыз.
Маһруй — күрше хатыны. Җырга, биюгә оста.
Зәйнәп — мәктәп кызы, Бануның кордашы.
Мәрьям — мәктәп кызы, Бануның иптәше.
Фатиха, Әсма — Бануның иптәш кызлары.
Хәйрия, Камил, Әхмәт — забитләр.

---

*Хосусән* — бигрәк тә, аеруча.
*Мөһаҗәрәт* — эмиграция.
*Мәгаттәәссеф* — үкенечкә каршы.
*Имкян* — мөмкинлек.
*Тәхсыйс итү* — тәгаенләү, файдалану.
*Забыт* — әсир.
*Забит* — офицер.

Фазыл
Хәбир } — егетләр
Вахит

Галимә — асрау.
Гөлсем — хатын доктор.
Әсир — мажар.
Тимер — Банунын бишектәге баласы.
Хәзрәт, комиссар һәм кызыл солдатлар.

Вакыйга Казанда сугыш вакытында.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур гына агач өй. Дивар кәгазьләнмәгән. Урта байларча җиһаз. Уртада түгәрәк өстәл. Тәрәзә араларында озын көзгеләр. Кыш көне. Эңгер-меңгер чак. Сәхнәгә каршы итеп, өстәл янына Кәримә абыстай утырган. Сул якта, ишек янында гына посыбрак Разыя утырган. Разыяның башында шәл, үзе качыбрак утыра. Уң якта Хәйрулла. Ул кием-салымын салмаенча гына утырган. Пәрдә күтәрелгәндә ут ягылмаган.

Кәримә. Менә шулай инде, үзеңез сөйләшеп, уйлашып караңыз.

Хәйрулла. Шулай инде, Кәримә абыстай әйтмешли, үземезгә кала, абыстай эшне белми түгел, аның әйткән сүзен тыңлыймыз инде.

Разыя. Минем җавап шул бер инде, илтифатыңызга бик рәхмәт. Мин кабул итә алмыйм.

Кәримә. Ул сүзне инде мин Хәйруллага әйттем, кызым, ул җавап аның күңеленә тулып бетми, бәлки уйлашкансың, киңәшкәнсең, истихарә иткәнсең... Бәлки...

Хәйрулла. Юк инде, абыстай, ул җавап җавап түгел инде, мин аны ишеттем инде, яңы бер сүз әйт инде, яңы бер сүз! Монда бит яшерен-батырын түгел, һәрнәрсә күз алдында, әйе, күз алдында...

Разыя. Беләм, беләм.

Хәйрулла. Әле мин бит азгынлыктан хатын өстенә хатын эзләмим, үзең беләсең, тәкъдир шулай, күрәсең. Көтмәгәндә үлде дә китте, Мәхфузә үләр дип кем уйлый иде... Үлгән артыннан үлеп булмый, менә, абыстай, рәхим итеп, син кабул ит инде!

Разыя. Мине бик авыр хәлгә куясыз, Хәйрулла абзый.

Кәримә. Монда ни авыры бар, дөньяда үлмәк тә бар, калмак та бар. Бу — бер тол ир. Син — бер тол хатын... Машина белән ясасаң, болай пар килмәс.

---

*Истихарә иту* — төш кую; ният итеп, җавапны төштә күрү.

Хәйрулла. Аннан соң, балалар өстенә дисәң, балаларны үзең беләсең, абыстай, үзләре таза, үзләре тәрбияле, үзләре ягымлы, Алла кушса, сине үз аналары кебек күрерләр.

Разыя. Беләм, Хәйрулла абзый, барысын да беләм, үзеңә каршы да, балаларыңа каршы да әйтер сүзем юк. Ләкин шулай инде, мин үземә, үземне шул бердәнбер баламны тәрбиягә багышлыйм, дип сүз биргән инде.

Кәримә. Ул бит сине балаңнан аерылырга сорамый, кызым!

Хәйрулла. Юк, Алла теләсә, Алла теләсә, минем өстемә төшкәнен туган атасыннан ким кылмам. Сиңа каршы, бу баланы ник болай итәсең, дип көнчелегем һич булмас. Беләсең, мин дә балалар атасы, миңа да җиңел түгел. Ул унбиш ел бергә гомер иткән балалар анасыннан аерылу бик уңай түгел. Аны сөйлиләр генә... Алла күрсәтмәсен! Инде нишлисең, җирләгәнгә бит өч ай булды... Балаларга да күз-колак кирәк бит. Үзем дә, әлхәмдүлиллаһ, яшь булмасам да, әле үз хәлем үземдә.

Кәримә. Бик һәйбәт булыр, кызым, оя корган кош кебек күңелең тынычлап китәр, кызым.

Разыя. Әйтерең бармы? Барысы дә дөрест, бик шулай, ләкин шул кызымны уйладым исә тагы «Юк!» дигән җавап авызга килә дә тора.

Хәйрулла. Шул, кызым, кызым, дисең, абыстай! Кызыңа ни буладыр, ди? Ул бит курчак уенын да үзгәртми. Аңарга да бит мин тагы ят кеше түгел. Әлхәмдүлиллаһ, өч ел бер капканы ачып-ябып йөримез, гадәтем, йолам — һәммәсе бит күз алдыңызда. Мәхфузә белә бер генә тәмсез әйткәнне ишеттеңезме? Бербер азып-тузып кайтканымны күрдеңезме? Бар бозыклыгым булса, инде шул, үземезнең театрдан калмыйм, анда бит хәзер ил-көн йөри.

Разыя. Юк инде, Хәйрулла абзый, булмый инде, күңелеңезгә авыр алмаңыз, булмый! Кеше сайлаудан түгел, кияүгә чыкмам дигән вәгъдәм бар иде...

Кәримә. Кемгә, кызым, вәгъдәң бар? Мин алай галим кеше түгел, ләкин китапта алай хәләл никяхтан тотып кала торган вәгъдәне белмим. Мин белмим... Беләм, кызым, балаңны бик яратасың, аның да хакы бар. Үзеңнең дә хакың бар бит... Бала күңеле өчен үзеңне-үзең көчләргә ярыймы икән? Дөнья бу, көннең яхшысы бар, яманы бар, бер-бер авырлыкка килгәндә, кемгә үз итеп тел ачарсың? Беләсең, нинди көннәр... Дөнья бит канга баткан!

Хәйрулла. Менә шулай шул, мин дә шуны әйтмәкче идем. Әле синең балаң булса, минем дә балаларым бар, сиңа авырлык килсә, мин бар, миңа авырлык килсә, син бар дигән кебек...

Разыя. Бар да дөрест, ләкин... Булмый! Рәхмәт икенезгә дә. Булмый инде, гаепләштән булмасын, Хәйрулла абзый, элгәреге кебек дуст күршеләр генә булып калыйк инде...

Хәйрулла *(аягүрә торып)*. Өндәмәк бар, күтәрмәк юк. *(Үзе туктап тора.)*

Кәримә. Шулай, шулай. Әллә, кызым, берәр истихарә кылып карыйсыңмы? Хәйрулла бит үз кеше, ул көтәр...

Хәйрулла. Андый бер йылы сүзе булса, көтәм, көтәм! Кардәш-кабиләсенә киңәшләшәме, туган иленә барып, ата-анасына зиярәт итеп киләме, көтәм, өч ай көттек инде, тагы көтәм...

Разыя. Юк инде, көтмә инде, Хәйрулла абзый! Бүген бу сүзнең ахыры булсын инде, рәнҗемә *(күзеннән яшен сөртә)*.

Хәйрулла *(китә башлап)*. Ярый, хушыңыз. *(Ишек төбенә җиткәч тагы борылып.)* Әле дим, абызтай, андый-мондый сүз-фәлән ишетелеп, дәүләтемә кызыга дип уйламыйсыңмы? Күңелемә дә кереп чыкканы юк. Алла теләсә, Алла теләсә, бу көнге көндә мин синнән өч мәртәбә бай. Фатирда торуыма карама, бер тиен бурычым юк, бөтен кибетем үземнеке, алай-болай күңелең шикләнә икән, менә тот та нотариус белән бөтен малыңны кызыңа яздыр, ягъни мәсәлән, иртәгә үзем мулласы кирәксә — мулласын, нотариусы кирәксә — нотариусын китерим дә яздырыйм!

Разыя *(башын селкеп)*. Әйткәнемчә, Хәйрулла абзый! Гаеп итмә!

Хәйрулла. Хушыңыз, хуш, Кәримә абызтай.

Хәйрулла чыгып китә. Кәримә дә аякка калка, икесе дә аяк өстендә.

Кәримә. Миңа да кайтырга вакыт! Хәерле булсын, кызым, бик зур адым атладың, ай-һай көчең җитәрме икән? Дөнья үткәрү бик авыр бит, кызым! Күңел төшү дигән эш тә бар. Нәфес теләү дигән нәрсә дә бар, эч пошу дигән уңайсызлык та бар. Белмим, кызым, белмим... Бу озын көннең рузасы кебек нәрсә инде. Сусарсың да, ачыгырсың да... Ярый ахшамына барып җитә алсаң! Аннан, кызым, үзең таза, үзең яшь. Әле җегәрендәге бер хатын... Шулай итеп, дөньяның ләззәтеннән, Алланың хәләл иткән

нигъмәтеннән үзеңне-үзең мәхрүм итүдән ни файда туар икән?

Р а з ы я. Балам бар, Кәримә абыстай, балам! Шуны тәрбияләп, шуны үстерим, шуның күңелен кырмыйм, шуны кеше ясыйм, дим. Аннан соң, насыйп булса, йортка кертермен. Бергә-бергә киченермез, дим.

К ә р и м ә. Бик озыннан уйлыйсың икән, кызым! Ләкин шул корбанның кадерен балаң беләчәкме? Аның үз тормышы бер чәчәк атса, үз язмышы алдына килеп басса, ул сине уйлап торачакмы? Мин аңлап бетерә алмыйм. Дөрест, баланың күңеле калмый булмый. Ләкин Хәйрулланыкы да дөрест бит. Икеңезнеке дә дөрест. Шунысы гаҗәп, ике дөресттән бер яңлыш туа, Алла үзе тугры юл күрсәтсен! Хуш, кызым. *(Чыгып китә.)*

Р а з ы я *(ялгыз, өстәлгә таяна да еглый)* Өч ел бербуйдан теш кысып юксыллыкка өйрәнүем тагы җимерелде, җәрәхәтем тагы ачылды. Тагы күңелем төрләнде. Ай нәфес... Ай нәфес! Бәлки аның балалары минем балаларым булып, яңадан оя ясап, элгәреге тормышымнан да тулы торыр идем, бәлки аның балаларына ана булып, кызыма да ата табып, тормышымны мәгънәләндергән булыр идем, бәйрәмендә бәйрәмчә чупырдашып, хәсрәтендә кайгылыча еглашып, гөрләп гомер итәр идем... Әллә эш үтмәс борын кабул итимме? *(Идән буйлап йөри.)* Әллә? Әллә... Белмим... Белмим! И Раббем! Ник син мине болай авыр табигатьле яраттың? Ник мин башкалар кеби кайгысын да, шатлыгын да өсттән генә үтә алмыйм? Әллә: «Хәйрулла абзый, кабул иттем!»— диимме? Мескен, бөтенләй җанланыр иде. Шатлыгына сыймас иде. Аннан балалар карар идем... Аннан үз балам булып, берәр угылым булса, шәкерт итәр идем... Әллә әйтимме? *(Ишеккә таба бара башлый, туктый. Еглаган тавыш белә.)* Әйтеңез! Нишлим? Кызыммы? Үземме?

Ишек ачыла да мәктәп киеменнән Б а н у килеп керә.

Б а н у. Әү, әнием, мин... *(муенына асылына).* Әни, әни, ник еглыйсың? Әни, ник еглядың? Әнием, җаным, кирәкми, еглама, валлаһи еглама!

Р а з ы я. Юк, юк... Кызым, кызым! *(Килеп Бануны кочаклый да башларыннан үбәргә тотына.)* Кызым, кызым! Минем мәңгелек дустым, кызым! Мәңгегә аерылмый торган кызым...

Б а н у. Әнием, бәгырем! *(Бану да егларга тотына.)*

Р а з ы я. *(Бануны кочагыннан ычкындырып, авыр сулу алып).* Бетте, кызым. Кичте. Җиле, уты кичте... Йә,

кызым, утыр! Ашыйсың киләме?

Бану *(еглаган тавыш белән)*. Килә иде дә, инде бетте!

Разыя. Йә, күзеңне сөрт... Галимә! Туташка аш керт!

Бану өстәл янына утыра. Разыя утны яга да җөен алып кызы янына утыра. Байтак вакыт берсе-берсенә карап тик утыралар. Галимә аш хәзерли.

Бану. Мин Хәлимә берлә бергә кайттым. Аның абыйсын солдатка алганнар.

Разыя. Кайчан?

Бану. Шул көннәрдә, төрек ягына йибәрмәсеннәр дип куркадыр, ди.

Разыя. Бу сугышы да бетмәде. Өч атнадан бетә дигәннәр иде, инде өч ай да үтте, елы да үтеп бара. Кем белсен, шәт, берничә елга тартылачак...

Бану. Фәхри мирзаның кызы сестра булып сугышка китә, ди.

Разыя. Тиле, монда эш беткәндер инде, шул урыс былчырагын юарга гына калгандыр. Бәрәкәтсез!

Бану *(аш ашый)*. Мин, әни, ашыйм да репетициягә барам. «Тиз кил!»— диделәр.

Разыя. Бетмәде шул репетицияңез дә! Син бит инде зур кыз! Алай иттереп, балалар кебек йөрергә ярамый.

Бану. Юк, әни, юк... Әсма да бара, Сафа Гайшәсе дә бара. Саҗидә кызы да бара. Аксак Шакир кызы да бара. Һәммәмез барамыз, без уйнамыймыз, без кодачалар гына булып чыгамыз *(ашап)*. Йә, туйдым моңардан. Әни, ник кабак бәлеше салмыйсың?

Разыя. Кыш көне кабак бәлеше буламыни? Алай аш төрлеләндермә! Ярый анаң куенында ни теләсәң, шуны бирәләр, кем белә, нинди йортка тап булырсың... Киявең кем булыр... Каенанаң кем булыр?!

Бану. Алла, кит, әни, кит... Мин кияүгә чыкмыйм, мин, әни, синнән аерылмыйм. *(Анасын килеп кочаклап үбеп.)* Юк, әни, китмим, кирәкми... Галимә! Галимә! Галимә! Әй, чукрак!

Галимә күренә.

Бану *(Галимәгә)*. Самавыр бир, тиз бул, берне генә эчәм дә китәм.

Разыя. Һәр кыз аны шулай итеп тора да, көне җиткәч аны сизми дә каласың. Һәркемнең башына килә торган бер эш, син генә читтә калмассың, Алла изгесен тугры китерсен!

Б а н у. Кирәкми, әни, сөйләмә шуны, кирәкми! *(Галимә чәй хәзерли, Разыя чәй пешерә. Бану ишек янына бара да идәнгә аягы берлә тибә, идәнгә ятып.)* Фатих! Шакирә! Ә! Ишетәмсез? Монда менеңез, монда! Гитарны алып мен! Ишетмим! *(Колагын куеп.)* Нәрсә?

Р а з ы я. Ни саташасың, йә кешеләре бардыр, Галимәне җибәрергә ярамыймыни?

Б а н у *(идәннән торып).* Бетте, әни, бетте, барышлый Зәйнәп белә Мәрьям, алып чыгармыз, дигәннәр иде, берәр генә мәртәбә, әни, репетиция ясап алырмыз.

Р а з ы я. Йә, утыр, чәеңне эч, көн буе ашамагансың бит, әнә нинди ябыккансың!

Б а н у *(көзгегә барып карап, чәчләрен төзәтеп).* Юк, әни, юк, аз гына бар. Минем чәчем, әни, тагы үсәрме икән, гәзитәдә бер чәч үстерә торган дару бар дигән, шуны алсаң иде!

Р а з ы я. Әйе шул, бар чәчең дә коелып бетәр иде. Вакытында ашасаң, вакытында эчсәң, ул үзеннән-үзе үсә.

Б а н у *(сүзендә дәвам итеп)* Бер май бар дигән, тирене йомшарта, йөзне нәфис итә, дигән.

Р а з ы я. Кайдан шундый юк-барны табасың?

Б а н у. Ник юк-бар булсын, әни, үземезнең гәзитәдә!

Р а з ы я. Бар да юк сүз, яшь кешегә һичбер дәва, дару кирәк түгел.

Ш а к и р ә белән Ф а т и х килеп керәләр, унар яшьле балалар, Фатихның кулында гитар, Бану чәчен ясый.

Ф а т и х, Ш а к и р ә. Исәнмесез, абыстай!

Р а з ы я. Аллага шөкер, йәңез, әйдәңез! Бик зур үсәсезме?

Фатих. Аллага шөкер!

Р а з ы я. Киленез монда. *(Икесенә дә чикләвек алып бирә. Бану һаман эшендә.)* Сабакны укыйсызмы?

Ш а к и р ә. Укыймыз, абыстай.

Р а з ы я. Әниеңезне сагынасызмы?

Ф а т и х. Бик сагынамыз, абыстай, әле җомга көн әти зияраткә алып барды, анда бик суык, әни, мескен, туңмыймы икән?

Р а з ы я. Юк, ул бит оҗмахта!

Ш а к и р ә. Оҗмах бит йылы, әйеме?

Б а н у. Йылы, йылы. Ул анда чәчәк күп, ул кош күп, ул асыл таш күп, ул энҗе-мәрҗән! Ул сарайлар! Ахактан сарай, гәүһәрдән сарай, нур уйный, кошлар

---

*Гитар* — гитара.
*Гәүһәр* — җәүһәр.

сайрый. Сулар, елгалар музыка уйный, яфраклар, агачлар бии! Гөлләр көйли!

Фатих. Анда йимеш, кәнфит, баллы кузак, чикләвек күптер?

Бану. Һәммәсе күп, һәммәсе...

Разыя. Менә әтиеңезнең сүзен тыңлап, сабакны тырышып укысаңыз, сез дә оҗмахка керерсез.

Фатих. Ник монда оҗмах булмаган? Тышта кар! Буран! Җил!

Бану. Урыс күпкә... Әнә төрек йортында алай түгел, анда кышы-җәе чәчәк, көзе-язы җимеш: алма, кавын, карбыз, йөзем... Монда да Сөембикә вакытында шулай булган.

Фатих. Шунда торсаң иде!

Зәйнәп, Мәрьям килеп керәләр. Берсенең кулында гитар, икенчесенең кулында балалайка.

[Алар.] Исәннәрмесез!

Разыя. Әйдәңез, туташлар, үзеңез исәннәрме?

Бану *(торып)*. Әйдәңез, чәй ясыймм ы?

Разыя. Кунактан, чәй ясыйммы, дип сорыйлармыни?

Бану. Алла, алар кунаклармыни? *(Зәйнәпкә күрсәтеп.)* Монысы — минем Алчәчәк, монысы — минем Сандугач.

Разыя. Кем булса да, синең ишегеңне ачып, бусагаңны бастымы, мөселман кеше — кунак!

Кызлар киемнәрен салалар, гитараларын куялар.

Зәйнәп. Миңа ясама, Алчәчәк! Хәзер генә эчтем, рәхмәт!

Мәрьям. Миңа да ясама, Сандугач!

Бану. Алла, берәрне эчеңез инде. Кирәкми? Алай булса, үпкәлим...

Разыя. Эчеңез берәрне, Бану да әле яңа гына эчә башлады.

Мәрьям. Рәхмәт. Без соңга калмыйк.

Бану чәйләр ясап куя.

Зәйнәп. Инде гитарлар тирләрләр. Кая әле, егет, синеке ни төсле? *(Фатихның гитарын алып чиртә башлый, бер көй чиртә.)* Менә бу яхшы гитар.

Һәммәсе гитарларын, балалайкаларын, цитраларын алып утыралар да «Галиябану» көен уйныйлар. Разыя тыңлап утыра, берсе пианинога утыра.

Бану. Шәпме, әни? Күңелле бит, ә?

Р а з ы я. Һәйбәт, бик һәйбәт... Җыры юкмыни?

Б а н у. Бар, бар. Беренче пәрдәдә хорымыз бар, йә, башла, Сандугач.

Мәрьям торып җырлый башлый, кызлар ахырына кушылалар.

Үтә, үтә, үтеп китә бу дөньяның көннәре,
Бетә, бетә, бетеп китә аллары да гөлләре..

Кызлар һаман уйныйлар, җырлыйлар. Шул арада ишек ачыла да урта яшьлек бер х а т ы н керә, кулында гармун.

М а һ р у й. Валлаһи, чыдый алмадым, кердем, гаеп итмәңез!

Р а з ы я. Йә, әйдә, уз!

М а һ р у й. Узам, узам, йәңез әле, туташлар! Миңа да урын бирегез! *(Галимә ишектән карап тора, Маһруй гармуны белән кушыла, уйнап беткәч.)* Без яшь чакта шул театры да булмады, өздергән булыр идем, валлаһи, тордык шунда дөмегеп...

Б а н у. Инде биеп карыйк! Әни, өстәлне күчерикме? *(Разыя тора. Кызлар урынны киңәйтәләр.)* Йә, Маһруй абызтай, бию көен син башла, нечкә тамыры белән генә, акрын гына уйна, болар кушылсын, без Алчәчәк белән биимез.

М а һ р у й. Бию көе! Бию көе күп ул, кайсысын? Әтнә көенме, Касыйм көенме? Менә тагы мишәр бию көе бар!

М ә р ь я м. Йә, берсен башла.

Маһруй бию көен уйный, ул бер катлагач, тегеләр кушылалар, ике кыз биергә тотыналар.

М а һ р у й. Бану, алай түгел, алай түгел, борылганда күбәләк кебек зыр-р әйлән! Шулай, шулай! Зәйнәп, чеметтереп ал, чеметтереп! Бармак очың беләнрәк бас, нәрсә мужик аты кебек аягыңны лапылдатасың? Шулай... Түгел... Нәрсә уклау йоткан кебек катткансың? Бөтен тәнеңне биет, һәммә әгъзаң биесен! Әй, юк ла. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, кыз булгансыз! *(Гармунын куеп.)* Йә, уйнаңыз әле! Менә ничек... *(Биергә тотына. Бер кат биегәннән соң.)* Йә, Бану, каршыма чык! *(Бану да каршы бии башлый.)* Шулай, шулай, башыңны күтәрә төш, ни йөзеңне әвене янган урыс төсле ясыйсың, күләргә хәзер кебек тот, ата торган чәчәк төсле бул! Йә, Зәйнәп, син чык! *(Зәйнәп бии башлый. Маһруй читтә басып.)* Шулай... Артка сыгылма... Алай икең ике очта тыпыр-тыпыр итеп торма! Бер-береңә якынаерга тырыш! Берең куган кебек булсын! *(Туктыйлар.)*

Р а з ы я. Бик һәйбәт ләбаса.

Мањруй. Һәйбәт, һәйбәт! Тагы нәфисрәк кирәк. Сез, кызлар, биюнең нәрсә икәнен беләсезме?

Мәрьям. Бию — бию инде. Анын нәрсәсе тагы?

Маһруй. Мәгънәсен беләсеңме?

Разыя. Аның тагы ни мәгънәсе? Ул китапмыни?

Маһруй. Ул бию — китапның китабы.

Зәйнәп, Бану. Йә, Маһруй абыстай, әйт, нәрсә?

Маһруй. Улмы? Ул, күңел ашкынганга чыдый алмаенча, күңелнең уй артыннан баруы, уй чаба, үр айгыры кебек чаба, язгы җил кебек чаба, бөтен тән, бөтен барлык аның артыннан тотам, тотам, дип чаба: уй сыгыла — бу сыгыла, уй иелә — бу иелә, уй еглый — бу еглый, уй көлә — бу көлә...

Бану. Ә минем күңелем ашкынмый!

Маһруй. Синеке ашкынмас, син анаң каныннан яратылган...

Разыя. Анасының күңеле ашкынмый димени?

Маһруй. Ашкынмый, ашкынмый! Ашкынса...

Разыя. Тик тор! Маһруй!

Маһруй. Торам. Тик торам... Куркынма!

Бану. Ашкынса, нишләр иде, Маһруй апа?

Маһруй. Ашкынса, нишләр иде? Ашкынса, болай дөмегеп тормас иде! Йә, кызлар, тагы берне биегез! Менә бу көйгә *(уйный)*.

Кызлар. Юк инде, соңга каламыз!

Маһруй. Азрак яшьрәк булмадым, гомер үтеп китте, мин күрсәтер идем. Без үскәндә бит шунда театры да булмады.

Зәйнәп. Маһруй абыстай, әйдә безнең белән! Бер генә көй биеп күрсәтерсең!

Маһруй. Кит, җүләр, хаҗи абзаң бирер кирәгеңне!

Мәрьям, Бану. Маһруй абыстай, әйдә инде, беркемгә дә әйтмәмез! Шәл ябынып биерсең!

Маһруй. Мин яшь вакытта да шәл ябынып биюдән туйган инде, юк, кызлар! Барыгыз! *(Кызлар киенәләр.)*

Разыя. Мин сиңа исем китә, Маһруй, дөньяны бигрәк җиңел күтәсең!

Маһруй. Дөнья барыбызга да бер, аны авыр күтәрсәң — авыр була, җиңелгә борсаң — җиңел була. Соң, әле кайгырып торып ни чыга дип беләсең? Аллага шөкер, Разыя, ачысын да күрдек, төчесен дә күрдек, өченче оя алыштырдым, уен түгел! Барысын да кайгырта башласаң, башыңдагы чәчең җитмәс. Тормышны түбеннән күтәрсәң дә — тәүлек егерме дүрт сәгать, өсттән үтсәң дә — егерме дүрт сәгать: бүгенге көн минеке, иртәгә?! Иртәгесен тагы шул ук кояш!

Разыя. Мин алай уйлый алмыйм.

Маһруй. Уйла! Тилермә! Алдыңа килгән нигъмәтне кире җибәрмә, үкенерсең, үкенерсең! *(Кызлар киенеп керәләр.)*

Фатих белән Шакирә. Хушыңыз, абыстай!

Разыя. Әтиеңез нишләп тора?

Шакирә. Әти әллә кайдан кайтты да башым авырта дип башын бәйләп ятты. Чәй дә эчмәде.

Разыя. Алай икән...

Маһруй. Алай шул, тегеләй булса, алай булмас иде. *(Кызлар киенгән көенчә.)*

Бану. Нәрсә, Маһруй абыстай, әнигә кирле-мырлы сөйләнәсең? Әни, ул ни сөйли?

Маһруй. Аны аңларга башың яшь әле!

Разыя. Берни юк, кызым. Тегеләй генә.

Кызлар. Хушыңыз! Хуш, Разыя абыстай, хуш, Маһруй абыстай!

Бану. Әни, хуш!

Разыя. Тиз кайт, кызым, башым авыртып тора.

Маһруй. Бер ачык ишектән мин дә чыгыйм. Хуш, Разыя! *(Бар да чыгып китә.)*

Разыя *(ялгыз идән уртасына баскан да)*. Башы авыртып яткан, ди... Башын бәйләп яткан, ди... У-у... Суык... суык *(шаленә төренә)*. Суык *(тешләрен шакылдата)*. Суык... Туңам! Туңам...

Тышта җил улавы, буран уйнавы ишетелә. Су юллары, морҗалар сызгыра, тәрәзә капкачлары шакылдый.

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ел ярымнан соң. Шул ук өй. Бүлмәдә бик күп ут янган. Пәрдә ачылганда Асрау гына өстәлләр рәтләп йөри.

Асрау. Иртә тор да шикәр кизүенә бар, аннан кайт та кирасин чиратына бар, аннан кайт та Печән базары буе, азрак дөге булмасмы, берәр генә әсмуха борыч булмасмы, берәр кадак кына сабын булмасмы дип, кибет саен теләнеп йөр. Үз акчаң өстеннән бит теләнеп йөрисең. Менә килде еллар! Шул ахыр замандыр инде! Бу падишаһны, каһәрне, тиле диләр иде, дөрест чыкты... *(көлеп)*. Нимес белән сугышкан була бит, хәерче! Бөтен яшь егетләрне әрәм итеп бетерде, авылда бит күзгә

---

*Кизү* — бу урында: чират.

алырлык кеше калмаган, бөтен кыз утырып кала инде! *(Күзгедә төзәтенә, гәзитә алып.)* Йә, нәрсә яза икән? «Кавказ фронты, баш... командананнан». Бусы ни булды ди инде? Кешечә генә язсалар, ярамаган! *(Укый.)* «Безнең баһадир гаскәремез алга атлады, өч пулемет алды». Алды! Алса монда килер иде ул, ситсаның аршыны алтмыш тиенгә менмәс иде! Ялганчы! *(Тагы карап.)* «Кәҗәм югалды, кәкре мөгезле, озын йонлы... ак төсле, муенында кызыл тасмадан билгесе бар. Белгән кеше Тегәрҗеп урамында, сукыр суфи йортында тегүче Әхмәдуллага хәбәр бирсен!» Әйе, шул гына калды, ди, синең кәҗәңне эзләп йөрергә, ди, бик эзләрмен инде, эшем бетте, ди!

Разыя урам ишегеннән килеп керә.

Разыя *(киемнән).* Кайта-кайта эт булдым: өч трамвай җибәрдем, трамвайда энә төртергә урын юк... Сугышта кеше үлә диләр иде, бу сугыш кызык булды: бөтен дөнья кеше белән тулды, каян чыга бу... *(асрауга).* Инде син дә гәзитә укырга тотындыңмыни?

Асрау. Укырсың монда! Әле менә тагы 5 еллык солдат җыя, ди, ике агам, бер энем, бер җизнәм сугышта, әллә инде бу каһәр әтине дә алмакчы була... Абызтай! Бу — хатыннарга да ясамасмы икән? Урыс бит — тиле!

Разыя. Юкны сөйләмә!

Асрау. Юк димә, әнә теге дуктыр хатын бар иде бит, туташ авырганда килгән иде, шуны алганнар, ди.

Разыя. Ул дуктыр кеше, аны солдатка түгел, больницага алалар, аш-суыңны карадыңмы? Килә башларлар *(утырып).* У-уф, арыдым! Тагы бер вагун кеше китереп ташладылар, ашата-ашата йөдәп беттек, үзләре һәммәсе: «Без мөселман»,— ди, үзләре менә ник кенә бер авыз сүз белсен! «Исемең ничек?»— дип сорыйм: «Гайшә»,— ди, «Гайшә» дип язган да. Китаплары бар. Әллә нинди — әфәлем төрле телдә язылган! Аш беткәч бар да дога кылдылар. Һәммәсе, илаһем, зид фәзид укый. Бер муллалары бар. «Исеме ничек?»— дип сорадык: «Иван»,— ди.

Асрау. Иван... *(эче катып көлә).* Иван! Иван хәзрәт! Менә күрмәгәнеңне күр, Иван хәзрәт! Эһе-эһе...

Разыя. Поляк мөселманнар, ди. Шул, безнең кебек торганнар, ди, ахырдан урыс басып киткән дә, телләрен югалтканнар, ди...

---

*Әфәләм төрле* — әллә ни төрле.

Асрау. Мескеннәр! Җырлый да белмиләрме икән?

Разыя. Бер авыз сүз белмиләр!

Асрау. Без дә шулай булмамызмы икән, абыстай?

Разыя. Ник булыйк? Шулкадәр мәчет, мәктәп бар! Йә *(кызу-кызу тора)*, хәзер килерләр, мин азрак өстем-башымны алыштырыйм...

Разыя *(теге бүлмәдән)*. Борыч таптыңмы?

Асрау. Мең бәла белән ялынып-ялварып бер әсмуха алдым, бирмиләр. «Юк!»— ди. Теге сучы Фәтхи бар иде ләсак, безгә дә су китерә иде...

Разыя. Әйе?

Асрау. Шуның угылы әфисәр булган! Эчем катты! Кылыч таккан, чылтыр-чылтыр иткән була *(көлә, пауза)*... Казан арты Вәлиләр бар бит...

Разыя. Әйе?

Асрау. Кабан күле буенда, читек-кәвеш белән сату итәләр, шуның угылы авылларына мөәззин булган, ди.

Разыя. Була алса, бик булыр инде! Ярты Казан бай балалары Воткин заводына да эшче булып китәләр, җан һәркемгә газиз!

Ишектән Хәйрулла килеп керә, солдат киемендә.

Асрау *(аптырап кала)*. Бәй, Хәйрулла абзый!

Хәйрулла. Исәнме? Абыстай өйдәме?

Асрау. Өйдә, өйдә!

Разыя *(килеп чыга, башында шәле)*. Ә, Хәйрулла абзый, сез икән. Әйдә, узыңыз.

Хәйрулла узып утыра. Асрау чыгып китә.

Хәйрулла. Әле күрешеп чыгыйм, дидем, иртәгә, Алла язса, сәфәр инде, пахут чыгамыз инде, догада булыңыз!

Разыя. Алла үзе сакласын инде, бер дә соң хәстәрен күрә алмадыңызмы? Әле бит кайсысы анда язылды, кайсысы монда язылды.

Хәйрулла. Алданрак уйланылмады, әллә нигә дәрт кайтып китте, тормышның тәме бетте! Аннан минем бит азрак бүсерем бар иде, шуңарга ышандым, ул, каһәр, карамый да икән, ярый, гына, ди... Ул бит калганнарның да рәхәте юк! Әнә Вәли малае инде алты айда унсигез мәртәбә комиссиягә керде. Алла хәерле кылсын инде!

Разыя. Кибетне нишләдеңез?

Хәйрулла. Яптым, инде яптым! Мал да бетте бит,

---

*Әфәләм төрле* — әллә ни төрле.

бу сугыш та бит дөньяны корытты. Инде, шулай яптым инде. Өйдә Кәримә абызтай кала инде, кызы белә... Әле шулай аларга шикәреннән шикәрен, кирасин-фәләнен, һәммәсен бирәр еллык әзерләдем, сез дә балаларга күз-колак булыгыз инде, абызтай!

Разыя. Ярый, насыйп булса, үзеңез тизрәк кайтырга тырышыгыз инде, алай-болай акча белә бирәр эш эшләп булыр әле!

Хәйрулла. Үзем дә шуны өмет итәм инде... Әле, абызтай, үз кулым белән тапшырыйм дип кердем, менә бер еллык фатир хакы. Алай-болай балаларга акча җитми башласа, үземезнең Вәли абзыйларда акча калдырдым, элгәреге хуҗа бит инде, шулай һәммәсен үземчә рәтләдем, васыятемә кадәр яздырдым... Алай-болай, дим, андый-мондый эш булып китсә, үземезнең авылга мәктәп салырга әйттем, син дә шаһит булып тор! *(Акча бирә.)*

Разыя. Рәхмәт.

Хәйрулла. Бу нинди мәҗлес? Әллә туташны бирәсезме?

Разыя. Юк, андый нәрсә юк әле...

Хәйрулла. Яшьләр үсә бит, без картайдык. *(Сакалын күрсәтеп.)* Сакал агара.

Разыя. Мәхфузә үлгәч, ватыла төштеңез!

Хәйрулла. Шулай булды, тәрбия булмады.

Разыя. Өйләнмәдеңез дә...

Хәйрулла. Әйе, әйе, өйләнмәдем дә... *(Тик торалар. Бераздан.)* Ул өйләнү җиңел түгел икән... Былтыр сезнең белән сөйләшүдән соң башка бер йиргә сүз салдым, бик тиз вәгъдә алдым, колак сөенчесе бирештек. Никях көне җитте. «Мәҗлестә үзем утырам»,— дидем. Бардык... Имамнар килде, бабай буласы кеше: «Кияү, монда чык әле»,— дип, мәһәр хакында сүз берләштерергә дип, икенче бүлмәгә чакырып чыгарды. Шулай, ишек ачык. Миңа хатын булачак кеше утырган да сагыз чәйнәп тора... Йөрәгем «жу-у» итеп китте... Бүгенге көндә, шул сәгатьтә сагыз чәйнәгән хатыннан ни өмет итәсен, дидем... Шуннан: «Мин,— дидем,— бу эштән кайтып торам»,— дидем... Бөтен бүләкләрне калдырып, бөтен чыгышларын түләп, иллаллаһ башны коткардым. Көн үтте, ай үтте, аннан менә бусы килде... Син дә картайгансың, абызтай!

Разыя. Шулай инде, яшәрмимез...

Хәйрулла. Әле, дим, безнең буын тора белмәде... Йә, мин шулай картайдым инде... Син дә шулай тиккә картайдың...

Разыя. Дөрест.

Хәйрулла. Без шул кысырга картайдык! Кысырга... *(тик торалар)*. Әле, дим, сезнең туташтан, ул сезнең төсле булмас. Әле күпме яшендә: никадәр егетләр тирәсендә чабып йөри... Ул, теге кара егет, чибәр генә! Аның нияте юк түгел кебек... Әле бит, күз — дәрья, күрәсең.

Разыя. Белмим инде, Хәйрулла абзый, яшьләрнекен белмәссең... Галимә! Галимә! *(Галимә күренә.)* Чәй ясап керт әле!

Хәйрулла. Рәхмәт, рәхмәт...

Разыя. Ярамый алай, сезнең зур көнегез! Безнең дә... Әле бүген кызым: «Әни, кунаклар чакырыйк»,— диде дә... «Чакыр, кызым»,— дидем. Үзенең күңелендә әллә нәрсә бар, әйтмәкче дә булган кебек була. Үзе әйтә алмый...

Хәйрулла. Шулай диген...

Галимә чәй кертә, өстәл янына утыралар.

Хәйрулла. Яшьләрнең өстәлен бозабыз инде.

Разыя. Андый эш ул, картлар белән башланса, бәрәкәтлерәк була. Әле шул, кара егет дигәнең, күбрәк йөри инде, бусы да, бер көн теге килмәенчә калса, хәзер борынын сәлендерә. *(Икесе дә чәй эчәләр.)*

Хәйрулла. Үзе кем ди соң?

Разыя. Кырым егете... Мәскәүдә укыган, монда имтиханнарын бетерәдер, ди, адвокат булачак, ди.

Хәйрулла. Чибәр егет, чибәр күренә.

Разыя. Тәкъдир булса, ни әйтәсең! Мин инде үзем үз арадан берәр кеше йортка кертерменме дип уйлаган идем дә, эш безнеңчә йөрми бит.

Хәйрулла. Хәерлегә булсын! *(Дога кылып.)* Рәхмәт, хуш, абыстай! Әле, дим *(мәҗлескә күрсәтә)*, сез шатлык алдында торасыз, без — озын юлга. Арш-марш, очы юк, кырые юк, урыс өмәсенә чыгамыз... *(яшенә тыгыла)*. Күңел нечкә... Минем дә балалар кала... Кемгә кала? Ата юк, ана юк. Ага юк, тута юк... *(күзен сөртеп)*. Әле, дим, теге көнне, сез алай итмәгән булсаңыз! Болай булмас иде, дим...

Разыя. Рәнҗемә инде, Хәйрулла абзый, хаталык бездә...

Хәйрулла. Рәнҗүгә урыны юк... Алай да... Болай булмас иде... *(пауза, яшь эченнән)* Монда шатлык! Монда туй! *(Өенә күрсәтеп.)* Анда моңлык, ялгызлык,

---

*Иллаллаһ* — бу урында:көчкә генә, көч-хәл белән.

ятимлек! *(Еракка күрсәтеп.)* Тегендә сугыш. Канлы сугыш! Хуш! *(Чыгып китә.)*

Р а з ы я. Изге юлга! Исән йөреп, сау кайт. *(Үзе үкереп еглый. Пауза. Акрын гына басып хатын-кыз ягыннан Кәримә килеп керә.)*

К ә р и м ә. Әллә беркем дә юк?

Р а з ы я *(күзен сөртеп)*. Бар, Кәримә абыстай!

К ә р и м ә *(бераз катып тора)*. Әйе, шулай шул, инде үткән эшкә салават, Разыя! Ул вакытта ук әйттем мин!

Р а з ы я. Әйттең, Кәримә абыстай... Шул, кызым!

К ә р и м ә. Әйе шул, кызың... Әле менә тагы шул кызың! *(Янына килеп карана.)* Беркем дә юкмы?

Р а з ы я. Юк, юк.

К ә р и м ә. Театрга барышлый кызың, әле, дим, миңа керде... Әби, ди, мин кайтканчы, ди, әни белән сөйләшеп куя күр, ди, үзем, ди, сөйләргә оялам, ди. Теге егет... Кем әле исеме?

Р а з ы я. Бәкер.

К ә р и м ә. Әйе, шулай... Бик сорый, ди, ул бүген, ди, әнидән рөхсәт сораячак, ди, әни риза була күрсен лә, ди... Менә ни, ди... *(Тик торалар.)* Йә, ник тик торасың?

Р а з ы я. Нишлим, Кәримә абыстай, тик торудан башка нишли алам? Үзең беләсең, шул балага дип бөтен гомеремне фида иттем. Үстерим, кеше ясыйм, дидем, әле бит бәндәчелек, йортка кертермен-фәлән дә, бергә чупырдашып торырмыз дип уйлый идем... Үз тормышым булмагач, аның тормышы янына сырылып, аның ирен угыл ясап, балаларын бала ясап торырмын дип уйлаган идем... Инде менә бу болай булды! Йә, тик тормый нишлим? Кырымга, ди бит... Кырымга! Кош очып кош җитә алмас бит! Мин хәзер җеп очымны югалттым...

К ә р и м ә. Югалтырсың, анысы да дөрест, ләкин, кызым, инде теге көнне ясаган ялгышны бүген икенче төрле иттереп ясарга ярамый, беләсең, замананың балалары: «Анам разый түгел!»— дип карап тормыйлар. Тәмсезлек чыкмасын! Инде балам өчен дип беренче корбанны кылгансың, икенчесеннән тартына алмыйсың!

Р а з ы я. Шулай, шулай, ләкин күңел бит сыкрый, Кәримә абыстай...

К ә р и м ә. Шулай, шулай... Алай син читкә какмыйсың, разый буласың?

Р а з ы я. Булмый нишли алам? Тешемне кысам да булам...

Кәримә. Изге эш булсын! Хәйрулланы озатырга кирәк. Хуш! *(Чыгып китә.)*

Разыя. Изге эш булсын! Бөтен өметемне баглаган бердәнбер балам... Бердәнбер кызым да китә... Мине ялгыз калдырып китә... Кырымга... Кырымга китә! *(Үкереп еглый.)*

Урам ишегеннән Бану, Зәйнәп килеп керәләр. Бану, әнисен күреп, әнисе алдына килеп баса.

Бану. Әни, ник еглыйсың? *(Әнисен кочаклап.)* Әни, бәгырем, ник еглыйсың?! *(Зәйнәп тик тора.)*

Разыя *(Бануның кочагыннан ычкынып)*. Ник еглыйсың? Әллә минем шатланырга хакым булмагач, хәсрәтләнергә дә хакым юк дип белдеңме? Мин дә кеше... Мин дә хатын!

Бану. Әнием, бәгырем, валлаһи, белмәдем... *(килеп кочаклап.)* Әнием, җаным, әнием, җаным! *(Еларга тотына.)*

Разыя, кызын кочаклап чәчләреннән үбә, икесе дә еглыйлар. Бераздан.

Разыя. Изгелеккә булсын, кызым, изгелеккә!

Шул арада ишектән бик күп кеше тавышы ишетелә. Разыя берлә Бану чыгып китәләр. Мәрьям, Фатиха, Әсма — җиткән кызлар, Камил, Әхмәт, Вахит — егетләр килеп керәләр. Камил белән Әхмәт — прапорщик киеменнән.

Егетләрнең берсе *(киемнәрен сала-сала)*. Тәмле ис чыккан!

Мәрьям. Бу Камил әфәнденең борыны бик нечкә! Сизгеч!

Камил. Шулай, бу сизә, моның борыны сизә! Менә Мәрьям туташның хушбуеның да кайдан чыкканлыгын сизә! Эһе-эһе...

Мәрьям. Бигрәк нечкәдән икәнсез! *(Чишенеп керәләр.)*

Зәйнәп. Әйдәңез, кунаклар!

Әхмәт *(читкә каранып)*. Бу соң сезне кияүгә бирәбезмени, Зәйнәп туташ?

Зәйнәп. Әйе, мине...

Әхмәт. Әйтсәңез лә, ул сезгә кияү булачак бәхетле егетнең исеме кем?

Зәйнәп. Аның исеме... Белмисезмени? Теләсәңез — сез! *(Башкалар көләләр.)*

Әхмәт. Мәгаттәәссеф, без падишаһ хезмәтендә грифтар!

---

*Мәгаттәәссеф* — үкенечкә каршы.

*Грифтар* — дучар, мәҗбүр.

Хәбир. Яңез, туташлар, театр күңелле булдымы?

Әсма. Минемчә, икенче пәрдә шәп чыкмады. Анда Садыйк ахырына кадәр каты торырга тиеш иде.

Зәйнәп. Хәйрия роле бик өсттән чыкты.

Вахит. Хуҗалар кая соң?

Зәйнәп. Хәзер чыгалар, киемнәрен генә алыштыралар.

Вахит. Мәслихәт, без гаскәри кеше — көтәргә өйрәнгән.

Фатиха. Вахит әфәнде, сезнең алай да кояш чыгарып торамы?

Вахит. Шулай, туташ, мин хәзер генә кояшны өстерәп төшерергә дип фәрман биреп килдем.

Бану килеп чыга.

Бану. Хуш килдеңез, кунаклар, рәхим итеңез!

Егетләр. Бик рәхим иттек, туташ.

Бану. Утырышыңыз!

Хәбир. Әле, димен, безнең барымызның хәлфәсе, барымызның остазы — самавыр килмәенчә утыру тәкәбберлек булып китәр, дип куркып торамыз.

Бану. Самавыр хәзер килә!

Разыя *(башына шәл салган)*. Исәннәрмесез, кунаклар!

Барысы да. Исәнмесез, Разыя абызтай, исәнмесез!

Разыя. Шулай бертөрле исән инде...

Хәбир. Бу — качакларга дигән ашханәңез һаман бармы әле?

Разыя. Бар... Алар да бик туйдырды. Бу поляк мөселманы дигәнең әллә нинди бернәрсә икән. Әле бит бушлай хезмәт итәмез, ашатамыз, эчертәмез, киемсалым бирдек... Көн дә бернәрсә арттыралар, бирмисез, дип орышалар. Әйтерсең лә, монда кода итеп чакырып китергәннәр!

Әхмәт. Шулай алар. Беркөн берсе безгә килгән: «Безне карамыйлар. Бу сугыш өчен корбан булдык, мөселманнар безне өрмәгән йиргә утыртмаска тиеш иде»,— диләр. Мин әйттем: «Ул бит, сугышны безнең мөселманнар башламады. Аларның файдасы өчен дә башланмады, бу сугышта урыс өмәсенә генә йөримез»,— дидем. Шуңар кәефе китте.

Разыя. Кунаклар килеп беттеме, кызым? Самавыр бирергә кирәк.

---

*Алай* — отряд, гаскәр.

Камил. Хәзер, абызтай, Бәкер әфәнделәр киләләр, бер йиргә генә кереп калдылар.

Разыя. Кунаклар, авырсынмасаңыз, бераз көтик!

Һәммәсе. Ник авырсыныйк?

Разыя. Әле театрдан арып чыккансыз, дим.

Төрлесе төрле йирдә сөйләшәләр.

Камил. Бераз арытты, пәрдәләре озынрак булды.

Бәкер, Фазыл килеп керәләр. Бәкернең кулында төргән әйбер бар. Фазыл кулында бернәрсә.

Бәкер. Әссәламе галәйкем!

Мондагылар. Вәгаләйкем әссәлам, син, иптәш, көттерәсең! *(Чишенеп керә.)*

Бәкер *(Разыяга)*. Исәнмесез, абызтай, сәламәтмесез!

Разыя. Үзеңез исән йөрисезме?

Бәкер *(бераз Кырым шивәсе белән сөйли)*. Аллага шөкер!

Разыя. Яңез, утырышыңыз, кунаклар.

Һәммәсе ничек утырырга аптырабрак торалар.

Әхмәт. Менә минем командам белән генә утырышыңыз әле. Мин бит әфисәр кеше. Яңез, марш! Бәкер әфәнде — монда. *(Аны утырта.)* Бану туташ! *(Аның янына утырта.)* Абызтай! Рәхим итеңез!

Разыя. Өй хуҗалары алай түргә менеп утырмыйлар, мин чәй ясыйм.

Зәйнәп. Мин ясыйм чәйне, абызтай, мин, утырыңыз! *(Разыя тартынып кына утыра.)*

Әхмәт. Яңез, туташлар, җаныңыз теләгән егет белән утырыңыз.

Көлешә-көлешә утырышалар, Галимә самавыр күтәреп керә.

Галимә. Исәннәрме, кунаклар!

Кунаклар. Аллага шөкер, үзең исәнме, Галимә!

Галимә. Булырсың монда исән, көненә дүрт чиратка барам, әфичәр булган булып торасыз! Ни дип монда шул аучтрине тутырдыңыз? Дөньяны тутырды, каһәрне!

Әхмәт. Менә фәрман биреп бөтен астрине куармыз.

Разыя. Теге әйберләрне керт, Галимә!

Галимә чыгып, бәлешләр кертә, Мәрьям, Зәйнәп чәй ясарга тотыналар.

---

*Аучтри, астри* — австрияле.

[А р а д а н  б е р с е]. Сезгә куемы?

[Б е р  к ы з]. Миңа сыек!

Б е р  к ы з. Миңа су гына, Зәйнәп!

Р а з ы я. Яңез, рәхим итеңез! *(Бәлешләр бүлеп-бүлеп бирә.)*

К а м и л. Сез дә, туташ, чәй эчмисезмени?

[Б е р  к ы з]. Юк, Камил әфәнде!

К а м и л. Кызганыч!

[Б е р  к ы з]. Ник?

К а м и л. Сезнең кулыңызны сорармын дип торадыр идем, инде болай булгач — бетте!

[Б е р  к ы з]. Ничек булгач?

К а м и л. Чәй эчмәгән кыз ул татар кызымыни? Аның белән ничек дөнья күтәрсең? Рәхәтләнеп, самавырны кайнатып, чәйне пешереп, дөньяны дер селкетмәгәч, мин ни дип өйләнеп торыйм?

М ә р ь я м. Сез хатынны чәй ясар өчен генә алмакчы буласыз икән!

К а м и л. Юк, аш пешерер өчен дә!

К ы з л а р. Менә гакыллы баш!

Бары да күршеләре белән сөйләшәләр.

Р а з ы я. Бу, сез гәзитә укый торган кешеләр, сугыш бетәме инде?

Х ә б и р. Һич очы-кырые күренми әле!

Б е р  т у т а ш. Төрек ягында эшләр ничек?

Х ә б и р. Хәзер начар түгел! Әле теге Дарданелдан кыйналып киткәч тә инглизләр аптырап калдылар.

М ә р ь я м. Йә, ул кызык булды, безнең әти, мескен, һәркөнне гәзитә хәбәре укып, Истанбул китә, дип коты очып тора иде. Беркөнне кияү егете кебек булып кайткан. «Нәрсә бар, әти?»— дим. «Теге мәлгуннәрне төрекләр, бик каты кыйнап, Дарданелдан кудылар»,— ди.

В а х и т. Ул һәммә йирдә бер бәйрәм булды!

Р а з ы я. Инде тизрәк бетсен иде!

К а м и л. Шулай иде дә бит, бик тирәнгә керделәр.

Һәммәсе чәй эчәләр, Бану белән Бәкер әллә нәрсә сөйләшә.

Ә х м ә т. Бәкер әфәнденең бер сүзе бар. Дикъкать, җәмәгать! *(Бәкер аякка калка.)*

Б ә к е р *(Разыяга карап)*. Хөрмәтле Разыя ханым! Мин үз илемнән читтә укучы бер егет. Сезнең өйдә бик күп кадер-хөрмәт күрдем. Шуларның һәммәсе өчен сезгә

тәшәккүр итәм! Инде менә, Аллага шөкер, имтиханнарны бетердем, шәкертлектән чыгып, халкыма хезмәткә керешергә вакыт җитте. Казанда яшәгән дәверемдә сезнең ике күзеңез Бану туташ берлә *(Бану башын ия)* таныштык. Холкын, табигатен өйрәндем... Ул да мине күрде, белде. Сез дә күрдеңез, ишеттеңез! Инде мин яңы тормыш алдында торам, насыйп булса, илемә кайтып адвокат булырга ниятләнәм. Шул юлда җиңеллек булсын өчен, тормышта барышырга иптәш булсын өчен Бану туташны рәфикалыкка чакырдым. Ул да, тәрбияле ананың тәрбияле баласы, сезнең рөхсәтеңезгә, сезнең фатихаңызга баглады. Менә мин сездән, түбәнчелек белән, газиз кызыңыз Бану туташны минем берлә бергә тормышын бүлешергә рөхсәт бирүеңезне үтенәм! Безнең күңелләремездәге бер-беремезгә каршы булган мәхәббәтемезнең шәргый юлга куелуына фатиха биреп, никяхымызга разый булсаңыз иде! Мин сездән шул олуг йомышны кире кайтармавыңызны бик үтенәм! *(Кызарып утыра. Тынлык.)*

Разыя. Рәхмәт, Бәкер әфәнде, илтифатыңызга! Мондый олуг эшне башлаганда ата-ананың фатихасы беренче урында... Әтиләреңез-әниләреңездән фатиха алдыңызмы соң?

Бәкер. Алдым. Зур бер фатиха җибәргәннәр һәм дә килен бикәне тизрәк алып кайт, дигәннәр. Алар дүрт күз белән яшь киленне көтәләр.

Разыя. Кызым ятим үсте, әтисе юк, киңәшләшергә кешем юк. Сезне дә тануым, белүем күп түгел. Бу ниятеңез инде уйлап эшләгән бер эштер... Әле Бану минем бердәнбер кызым, минем бердәнбер иптәшем... Бу бер тол хатын, бер ятим кыз алдында уйнау гына түгелдер?

Бәкер. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, Разыя ханым!

Разыя *(тик тора, бераздан)*. Кызым үзе разый булгач, мин дә разый.

Бәкер торып Разыяның кулын үбә, төеннән алып Бануга ал чәчәк тәкъдим итә. Бану алгач, аның да кулын үбә.

Һәммә егетләр, кызлар. Мөбарәк булсын!

Бәкер *(Бануның кулын алып, аягүрә калкып)*. Абыстай, фатиха биреңез инде!

---

*Тәшәккүр итәм* — рәхмәт әйтәм.
*Рәфикалыкка* — хатынлыкка.
*Шәргый* — шәригатьчә.

Р а з ы я. Утырыңыз әле азрак... Галимә! *(Галимә керә.)* Бар, Хәйрулла абзыйны чакыр: «Абыстай, туташны вәгъдәләшәмез, хәзер үк дога мәҗлесенә рәхим итсен, дип әйтте»,— диең. *(Галимә чыга.)* Шунда бер урын хәзерләңез әле, ул сәфәр чыга торган кеше, күңеле боек кеше, догасының кабул була торган чагы.

Егетләр Разыяга каршы якта урын хәзерлиләр. Берсенә-берсе гаҗәпләнебрәк карашалар. Пауза.

Г а л и м ә *(бераздан кереп ачы тавыш белән).* Хәйрулла абзый пахут чыккан.

Р а з ы я. Пахут чыккан... Инде бусы пахут чыга! Йәңез, алай булса, бер дога кылыйк! Егетләр, туташлар! Кызым тормышның иң зур адымын атлый, нечкә сират күпереннән кичә, анасы кебек бәхетсез булмасын дип, һәммәңез догада булыңыз! *(Яшенә тыгыла.)* Бәкер әфәнде! Хатын-кыз ул зәгыйфь була. Минем кызым атасыз үсте, мин аны йомырка эчендәге сары кебек тәрбияләдем, инде шул әманәтне сиңа тапшырам, ире дә, дусты да, иптәше дә бул! Кызым! Бу көндә син ана куеныннан чыгасың, менә синең арка таяначагың, менә синең кайгы-шатлыгыңны бүлешүче! Син әле яшь, тәҗрибәсез! Аның сүзен тыңла, хәлфә кебек игътибар ит, аны олугла! Хыянәт итмә! Иреңнең гаебен күрмә! Үз гаебеңне күрсәтмә! Йәңез, бер дога!

Һәммәсе кул күтәрәләр. Догадан соң егетләр, кызлар килеп: «Мөбарәк булсын! Мөбарәк булсын!»— дип икесен дә котлыйлар. Бәкер икенче төенне алып Бануга бирә, аны ачып бүләкләр карамага тотыналар, бүлмә яныннан Маһруй күренә, кулында гармун.

М а һ р у й. Мине чакыручы булмаса да, туйдан калмыйм дип килдем, туй мөбарәк булсын! Туйдан тукмак та калмый, ди. Маһруй каламы? Борыны берлә боз тишеп тормыш оештырган Маһруй каламы?!

Р а з ы я. Әйдә, рәхим ит, Маһруй!

К ы з л а р. Рәхим ит, Маһруй абыстай!

Е г е т л ә р. Боерыңыз, абыстай!

М а һ р у й. Әйтәм, әйтәм *(утырып)*, дөньяда ике төрле кеше була: берсе — алдына килгән нигъмәтне ашый белми *(Бануга карап)*, әниең кебек. Берсе — чакырылмаган йиргә барып кереп карынын туйдыра *(үзенә күрсәтә)*. Менә, яшьләр, кеше кадерләгәнне көтеп тормаенча, үзеңезне үзеңез кадерләңез!

Е г е т л ә р, к ы з л а р. Шулай, Маһруй абыстай, бик шулай!

---

*Пахут чыккан*— походка киткән, гаскәргә алынган.

Маһруй. Йә, музыкаңыз бармы?

Утырып гармун уйнарга тотына. Бер кыз пианинога утыра, музыка башлана. Яшьләр һәммәсе парланалар, Хәйрулланың урыны буш тора, Разыя өстәл янында ялгыз кала.

Музыка эчендә акрын гына пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер ел вакыт үткән. Шул ук өй. Асрау тәрәзәләр алып йөри.

Асрау *(бер тәрәзәне алып)*. Менә нинди яктырып китте. Яз була башласа, күңел рәхәтләнеп китә. *(Карап.)* Әллә Хан мәсҗеде тирәсе яшәрә башлаган?! Безнең авылда кызлар киндер агарта торганнардыр, сабантуена хәзерләнә торганнардыр... Әй, бу ел сабантуе да булмас инде, анда мәйданда көрәшергә кеше дә калмаган! Малай-салайны гына кәнфит-перәннеккә көрәштермәсәң? Кыз китеп, килен килмәгәч, сөлге җыярга да урын юк! Чабыштырырга ат та беткән, барысын казнага алып бетергәннәр... Өч ел бит! Бу тилесе һаман сугышкан була, ярты йирне биреп бетерде инде! *(Үзе «Герман көен» җырлый.)*

Ак Иделгә төшәрсең, колач салып йөзәрсең,
Күке кычкырган чакларда ничек итеп түзәрсең?

Маһруй *(икенче өй тәрәзәсеннән кычкыра)*. Галимә! Бик моң йырлыйсың, берәр егетне соклandырмакчы буламсың әллә?

Галимә. Нинди егет? Егет калдымыни?! Аучтригә башка йортта ир дә юк!

Маһруй. Көн нинди матур! Кояш нуры уйный!

Галимә. Сыерчык килмәгәнме, Маһруй абызтай?

Маһруй. Юк әле. Әле бит ел бик иртә... Гармун уйнап җибәримме, йырлыймсың?

Галимә. Әйдә, әйттер! Шулай да күңелне ачмасаң...

Маһруй гармун уйный, Галимә сугыш көен йырлый, бүлмә ягыннан Кәримә килеп керә.

Кәримә. Разыя кайтмадымы?

Галимә *(һаман эшли)*. Юк әле, Кәримә абызтай. Үзем дә көтәм инде. Эш юктан эш табып йөри инде шунда. Теге полякларыннан бушангач, азрак тынып калган иде. Инде тагы мөселман лазаретына йөрергә тотынды. Шул солдат пычрагыннан нинди рәхәт таба торгандыр!

Кәримә. Алай димә, алар да адәм баласы, алар бит үз ихтыяры белә сугышка китмәгән... Банудан хат бармы?

Галимә. Бар иде, атна саен аламыз, туташның авыры бар, ди, угыл булса, Тимер кушамыз, дигәннәр.

Маһруй. Тимер, ди?! Әһе-әһе *(көлә)*. Менә тапканнар исем! Тимер! Икенчесе булса, Томыр кушарлар инде.

Кәримә. Ник, матур ич, ул бит Аксак Тимер дигән безнең бер батыр падишаһ булган, ул урысны бик кыйнаган...

Галимә *(кычкырып)*. Йә, Маһруй апа, ник туктадың?

Маһруй. Хәзрәт мәчеткә килә...

Кәримә. Разыя кайткач та миңа аяк берлән генә шакы әле, Галимә, йомышым бар, җәме!

Галимә. Ярый, Кәримә абыстай, самавырым сүнмәгәнме, карый кит әле!

Кәримә *(ерактан)*. Самавырың ташып беткән!

Галимә. Шулайдыр шул! *(Бер тәрәзәне күтәреп чыгып китә, сәхнә буш тора, Маһруйның гармуны гына ишетелә.)* Өем суынып киткән. *(Тәрәзәдән башын тыгып.)* Әстри! Әстри!

Әстри *(тыштан)*. Ә... Ә!

Галимә. Драва таскай!

Әстри. Ә?

Галимә. Утын керт, утын! *(Кулын бутап күрсәтә.)*

Әстри. Ә!

Галимә. Һичбер сүз аңлатыр хәл юк!

Австрияле әсир утын күтәреп керә, идәнгә ташлый.

Галимә. Куркыттың!

Әстри. Ә?

Галимә *(янына килеп)*. Ә, ә... Телсез учтри!

Әсир. Учтри, но учтри, но учтри! *(Күкрәгенә сугып.)* Мажар...

Галимә. Учтри.

Әсир. Но учтри, мажар... *(Сакалын күрсәтеп.)* Сакал... *(Кулын күрсәтеп.)* Әл, әл...

Галимә. Пәрәмәч, бу мөселманча белә!

Әсир *(балтасын күрсәтеп)*. Балта...

Галимә. Маһруй абыстай, учтри мөселманча белә!

Маһруй. Чынмы? Хәзер керәм. *(Ишектән гармун күтәреп керә.)*

Галимә. Твоя сакал...

---

*Әл* — кул.

Ә с и р. Сакал... *(Галимә кулын күрсәтә.)* Әл. *(Балтасын күрсәтеп)* Балта.

М а һ р у й. Әчтри, как твоя знай?

Ә с и р. Но учтри, мажар...

М а һ р у й. Мажар? Кем соң ул, Галимә, мажар? Твоя төрек?

Ә с и р. Но турка *(Маһруйга күрсәтеп.)* Турка! *(Галимәгә дә.)* Турка!

Г а л и м ә. Мажар, мажар, шайтан белде, ди, синең мажарыңны!

М а һ р у й. Әйе, әйе. Мажар башы дигән авыл бар Казан артында. *(Әсиргә.)* Твоя баранчук есть?* *(Әсир аңламый. Галимә кулы белән күрсәтеп, еглаган булып аңлата. Әсир башын ия.)* Ничә? *(Бармагы белән санап.)* Бер, ике, өч...

Ә с и р *(бармагы белән).* Ике! *(Кесәсен күрсәтеп.)* Юк!

Г а л и м ә. И моя нет.

Ә с и р *(карана, Маһруйга гармунын күрсәтеп).* Уйна!

Маһруй уйный, әсир пианинога күрсәтеп, уйнарга теләвен аңлата. Пианинога утырталар. Әсир Орду маршын уйный.

Г а л и м ә. Бу бит безнең театрда уйный торган төрек көен уйный.

Әсир көлә. Үзе һаман уйный.

Р а з ы я *(килеп керә).* Бөтен урамга тавышыңыз ишетелә, нинди җыен ясадыңыз?

Әсир туктый. Разыяга баш ия.

Г а л и м ә. Менә, абызтакаем, бик оста иттереп безнең көйне уйный, аннан безнең сүзләрне белә...

Әсир көлеп тора.

Р а з ы я. Яп тәрәзәләреңне, өең аран кебек булган... Әйдә, Маһруй, чәй эчәрмез, уз...

М а һ р у й. Мин әзергә хәзер, әйе, моңарга исем китеп тора, тәмам безнеңчә уйный.

Р а з ы я. Самавырыңны керт! *(Галимә тәрәзәләрне ябып чыга.)* Йә, нәрсә уйный соң? *(Әсиргә)*: «Уйна!» — *(дип кулы белән күрсәтә, үзе киемнәрен салып утыра.)*

Әсир тагы төрек маршын уйный, Г а л и м ә самавыр кертә, Разыя чәй сала, әсир һаман уйный, К ә р и м ә килеп керә, кулына 11 яшьлек бер и р б а л а тоткан.

---

* Бу сүзләр оригиналда рус хәрефләре белән язылган.
*Орду* — гаскәр, армия.
*Аран* — абзар.

Кәримә. Исәннәрмесез!

Разыя. Әйдә! Хуш, Кәримә абыстай!

Ир бала. Бу безем марш! Орду!

Музыка янына бара да Орду көен йырларга тотына, әсир көлеп-көлеп уйный, малай йырлый.

Ордумыз этти йәмин, тетрәде хакы зәмин,
Милләти этти йәмин, ачылды раһы нәүйин.
Сәнҗагымыз — шанымыз, госманлы — гонванымыз,
Ватан бизим җанымыз, фәда олсун канымыз!

Хатыннар утырып, исләре китеп тыңлап торалар. Әсир уйный, малай җырлый. Туктагач

Разыя. Яхшы, яхшы! *(Әсиргә чәй ясап бирә, Галимә ашарга-эчәргә илтә, әсир урынында ашарга-эчәргә тотына.)*

Кәримә. Менә Печән базарына чыккан идем, бер мөселман солдаты: «Шул баланы алучы юкмы, төрек баласы, үзем белә бергә алып кайттым»,— дип кычкырып йөри. «Бир, угылым, алыйм»,— дидем, күңелемнән, Разыя, сине уйладым, менә, теләсәң, сиңа бер угыл.

Разыя. Кил, балам, исемең кем?

Бала. Шәүкәт.

Разыя. Атаң бармы? *(Бала аңламый.)* Анаң бармы?

Бала. Анам, әвәт, ханым әфәнде, анам варды, казак гәлди, өлдүрдү, бабам качды... гитти...

Кәримә. Күп сүзен аңлап була.

Разыя. Утыр! *(Бала утыра, чәй бирәләр.)* Син ничә яшьтә?

Бала. Кач яшта? Онбирдә.

Галимә. Тәмам безнеңчә сөйли!

Разыя. Безнеңчә сөйләми — бер халык бит! Агаң бармы?

Шәүкәт. Ага варды, Хәлим ага диорларде, әрмәни гәлди — кәсти, җами варды... казак гәлди — якды.

---

*Этти йәмин* — ант итте.
*Хакы зәмин* — җир туфрагы.
*Раһ* — юл.
*Нәүйин* — яшьләр.
*Сәнҗак* — байрак.
*Шан* — дан.
*Гонван* — дәрәҗә атамасы. Титул.
*Фәда* — фида, корбан.
*Әвәт* — әйе.
*Баба* — эти.

Кәримә. Үзе бик оста сөйли, сөйләсен әле? Йә, угылым, сөйлә, ни булды?

Шәүкәт. Ни булдымы дисең? Кышкы көн иде, бәйрәм булды... Барабан кактылар. Хәрби марш җырлап солдат килде... Авылда туй булды. Кәнфитләр бик күп иде. Мәчет янына баргач, манарасында кызыл байрак күрдек. Имам дога кылды... Шуннан генерал килеп чыкты. Үзе ак атка атланган, кылычы алтын...

«Угланнарым,— диде,— падишаһ сезгә сәлам әйтә». Һәммәсе дә: «Падишаһыбыз, мең яшә!»— дип кычкырдылар. Барысына да мылтык бирделәр. Күрше Хәмит тә, җимешче Әхмәт тә, әтием дә мылтык алдылар. «Миңа да бир» дигәч, «син әле кечкенә, балам» дип җавап бирде... Бераздан соң бик күп солдат килде, тагын килде, тагын. Безнең өйгә дә офицерлар урнашты. Әнием пылау пешерде, ит кыздырды, йогырт белән сыйлады кунакларны... Бик зур бәйрәм булды. Шуннан хәрбиләр тауларга менеп киттеләр... Иртән иртүк мылтык тавышлары ишетелә башлады, әтием аларны ишеткәч йөзе агарды. «Улым, өйдән чыкма, сугыш бара, казаклар килә»,— диде. Туп-мылтык гөрселдәп кенә торды. Бер заман кычкыру тавышлары ишетелә башлады. Авылыбызга казаклар кереп тулды. Әтием мылтыгын алып таулар арасына китте, без калдык... Төнлә йоклый алмадык. Иртәгесе көнне бөтен балалар һәм хатыннар мәчеткә җыелды. Анда да казаклар килде, әрмәннәр килде, мылтыктан гөрс-гөрс аттылар... Әнием кычкырып җибәрде. «Ля илаһе илля Аллаһе» дип укына башлады. Мылтыклар бертуктаусыз гөрселдәде, мәчет эче төтен белән тулды, мин идәнгә егылдым... Әниемне күрдем: ул идәндә кан эчендә ята иде... Сеңелем дә канга буялган иде. Әнием миңа: «Шәүкәт»,— диде, кулы белән кочаклады. «Аллаһ, Аллаһ» диде... Аннан тынсыз булды... Янә әрмәннәр килде, мылтык аткан тавышлар ишетелде. Дөнья төтен белән тулды... Күршебез Хәлимә ханым да, имамның хатыны Әсма ханым да, Бәкер килене Фәбрия дә — һәммәсе үлгән иде. Мәчет эчендә суык... Мине бер рус казагы алып китте. Бик еракка киттек. Хастаханәгә эләктем. Гали исемле бер кеше мине үзенә алды, ул да ярасыннан үлде, мине кулсыз Хәмиткә калдырды.

---

*Кәсти* — кисте, үтерде.
*Җами варды* — мәчет бар иде.
*Гәлди — якды* — килде — яндырды.

Анысы да мине башка берәүгә калдырып китте. Аннан соң Фатих исемле бер кеше белән поездга мендек. Анда да бик салкын иде. Бардык, әллә никадәр күп бардык, юлда йокладык. Аннан инде менә монда килдек. Карасак, төрек шәһәре икән, мәчетләр дә бар. Ханым әфәнде, минем әти тиз киләчәкме?*

Разыя. Киләчәк, киләчәк.

Шәүкәт. Бән мәктәбә гидәрем, соңра забит олурум. Соңра паша олурум, бәм-бәяз ата бинәрем...

Хатыннар. Мескен ятим!

Кәримә. Шулай...

Разыя. Гәзитәләр бик күп бала ятим калды дип язганнар иде, шуларның берсе инде... Ярый, бездә торсын, иптәш булыр. *(Балага.)* Угылым, укый беләмсең?

Аустри чынаягын шылтырата төшә, Галимә аңарга тагы чәй ясап бирә.

Шәүкәт. Билийорум...

Разыя *(Галимәгә)*. Бар әле, бер китап китер! *(Галимә китап китерә.)*

Шәүкәт *(укырга тотына)*. Мин мәктәпкә барам, мәктәптә сабак укыйм...

Разыя. Ярый, ярый, йә чәеңне эч инде! Син инде атаң...

Кәримә. Бабаң, диең.

Разыя. Бабаң килгәнче бездә торырсың.

Шәүкәт. Чәй эчеп, ашап турырмын, бән мәктәбә гидәрем.

Разыя. Мәктәпкә дә китәрсең.

Кәримә. Бу сугышта никадәр халык әрәм булды, әле Аллага шөкер, сугышлар ерак булды, диеңез!

Ишек кагалар.

Галимә. Чыгам, чыгам! *(Чыгып китә. Бераздан бер хат, берничә гәзитә күтәреп керә.)* Почта!

Разыя. Банулардандыр. *(Ачып укырга тотына, тик торалар, Разыя укый.)*

Кәримә. Ни бар?

Разыя. Һәммәмез сәламәт, Бәкерне солдатка чакырганнар иде, комиссия өч айга калдырды, дигән... Анда да солдат барып җитте...

---

* Шәүкәтнең бу хикәяләве төрек теленнән тоташ тәрҗемә итеп бирелә.

*Забит* — офицер.

*Бәм-бәяз ата бинәрем* — ап-ак атка менәрмен.

Шул арада бүлмә ягыннан тавыш чыга. Шакирә, Фатих еглашып килеп керәләр, кулларында хат.

Балалар. Әби, әби, әти үлгән. Әти сугышта үлгән, әти үлгән, әтием, бәгырем, үлгән!

Һәммәсе аягүрә сикереп тора, әсир дә тора, катып торалар.

Кәримә. Юк, бәбкәм, юк сүз, әтиең үләме соң?!

Шакирә. Үлгән, үлгән, менә хаты. И Алла, и Алла, элгәре әни үлде, әнисез калдык... Инде әти үлде... Ятим калдык! *(Үкереп еглыйлар.)*

Разыя хатны алып, укырга куркып катып тора.

Кәримә. Укы инде!

Разыя *(яшь эчендә)*. «Сезгә, гыйззәтле балаларга, без ки Спас өязе, Роман волосте, Карга авылының Әхмәтҗан Мөхәммәтҗаннан бик күп сәлам. Вә кинә мәгълүм итәмен, сезнең атаңыз Хәйрулла Хисаметдин угылы Фәхретдинов солдат третьева стрелкового его величества царевича полка февральнең икенче көнендә булган сугышта Австрия фронтында каты җәрәхәтләнеп, икенче көнне больницада җанын тәслим итте... Васыяте буенча эш итәргә кушты. Аллаһе Тәгалә рәхмәтендә калсын. Моны язгучы Әхмәтҗан Мөхәммәтҗан угылы дип беләсезләр, исән-сау кайтса иде, дип дога кыласызлар...»

Һәммәсе еглый.

Кәримә *(кулын күтәреп)*. Иннә лиләйһи вә иннә иләйһи раҗигун.

Галимә *(әсиргә барып, өстәлгә сугып)*. Синең учтриләрең үтергән! Ник үтерденез? *(Балаларга күрсәтеп)*. Болар нишләр?

Әсир *(аптырап тора)*. Нет учтри, нет учтри... Мажар.

Шәүкәт *(Фатихның янына барып)*. Бәнем дә анам олдү, һәмширәм олдү... Еглама! Мәктәбә бәрабәр гидәрез... Забит олурсун.

Кәримә *(торып, балаларны алып чыгып китә.)* Юк,дөрест түгел, угылым, дөрест түгел! Бу юк хәбәр генә, кем белә... Бит андый яңлыш хатлар була!

Еглый-еглый китәләр, Маһруй гармунын яшереп кенә алып чыга, әсир дә акрын гына югала. Разыя, Шәүкәт калалар. Разыя үкереп егларга тотына.

---

*Кинә* — янә.
*Мәктәбә бәрабәр гидәрез* — мәктәпкә бергә барырбыз.

Р а з ы я. Әй, мескен! Әй мескен! Күз алдымда басып тора, мескен! Менә шунда утырып бит чәй эчте. «Хуш, сау булыгыз, минем дә балаларга күз-колак булыгыз!»— диде... «Әле, ди, тормышның тәме бетте дә... артык артыннан да йөрмәдем, китәм, пахут чыгам инде»,— ди. Үзе яшенә тыгылган... «Хушыгыз, бәхил булыгыз, теге көнне тегеләй булмаса, бәлки бүген болай булмас иде»,— ди. Тугры, тугры, ул көнне ул алай булмаса, бүген ул болай булмас иде. Ул әллә кайда читтә урыс арасында үлеп ятмас иде... Теге көнне алай булмаса, бүгенге көндә ул «Ясин»сыз җан биреп, җеназасыз, кәфенсез урыс мәзарлыгында үләксә кебек ташланмас иде... Бәхил бул, Хәйрулла абзый, бәхил бул! Бәхил бул! Мин гаепле... Мин сине балам өчен корбан иттем. Сине генә түгел, үземне дә... үземне дә корбан иттем... Бәхил бул! Рәнҗеп ятма! Бәхил бул! Анда үлсәң, син анда кан эчендә бугылып, балаларыңны күрергә тилмереп үлсәң, мин монда ялгызлыкта, ятимлектә буылам... Ялгызлыктан йөрәгем тугып, өшеп, кая барырга йир таба алмыйм, башымны кая куярга йир була алмыйм... Аның рәхәте, аның күңел тынычлыгы өчен сине, үземне, икемезнең дә киләчәгемезне, бәлки өй тулы матур-матур балаларны фида иткән кызым хәзер юк! Ул китте... Китте. Кырымга китте. Үзе өчен анасының нинди корбаннар ясаганын башына да кертеп чыгармаенча китте... Үзенең тормышы белә мәш булып китте... «Әни ялгыз кала. Әни ятим кала, әни сак кала»,— дип, бәлки, башына да кертеп чыгармады... Үзенең мәхәббәте белә исереп, мине дә онытты, ялгызлыгымны да күрмәде, күрә алмады! Рәнҗемим... Валлаһи, рәнҗемим... Рәхәт тор, кызым, рәхәт яшә, кызым... Сыныклык күрмә! Киткәндә, озатканда күңел өчен генә дә: «Әни, әйдә безнең белә»,— дигән бер генә сүз дә әйтмәде. Күңел өчен генә булса да әйтмәде...

Ш ә у к ә т. Ханым әфәнде, аглама! Ханым әфәнде, аглама!

Р а з ы я. Юк, балам, юк ич! Бетте... Кил монда! *(Шәукәтне сөеп.)* Менә монда бер ятим, тегендә ике ятим, шул ятим балалар арасында бер ятим карчык бер урын табар әле! Шул ятимнәр арасында бер ятим йылы булыр әле! Сез — бәхетлеләр, рәхәтеңездә булыңыз, сөеңез, сөелеңез, яшәңез! Без — үксезләр, ятимнәр,

---

*Мәзарлык* — каберлек.
*Сак калу* — сагаеп, боегып калу.

язмышның үги балалары, кайгырыйк, еглыйк, көйлик... *(Шәүкәткә.)* Угылым, тәһарәт төзи беләмсең?

Шәүкәт. Билийорум!

Разыя *(башыннан сыйпап)*. Бар, тәһарәт төз, Галимә! Галимә!

Галимә керә.

Галимә. Нәрсә?

Разыя. Бар, Кәримә абызтайга әйт, балалар белә тәһарәт төзеп менсеннәр, Хәйрулла абзыйга тәһлил укыймыз дип әйтте, диген. Маһруйга да әйт! Ашыңны күбрәк сал, балалар бүген бездә ашарлар!

Үзе дә тәһарәтләнергә чыга. Сәхнә буш тора. Бераздан битен сөртә-сөртә Разыя керә, аның артыннан Шәүкәт керә.

Шәүкәт. Бизим күйдә җами тарафында чәшмә варды, чок татлы сулу иди. Рамазанда бабам ла кандил бәйрәмендә гидәрдек, анам татлы япарды... Каймак вәрирди... Сахур гәлдекдә давул чаларларды.

Сызганган җиңен җибәрә-җибәрә Кәримә килеп керә, кулында тәсбихы. Аның артында балалар. Балалар икесе дә һаман еглаудан туктамаганнар.

Разыя *(башларыннан сыйпап)*. Килеңез, балалар! *(Маһруй да керә, намазлыклар җәяләр, һәммәсе идәнгә тезелешеп утыралар.)* Яңез, балалар, әтиеңезнең рухына бер тәһлил укыйк, ул исән булса, тиз кайтсын дип, үлгән булса, урыны оҗмахта булсын дип дога кылыйк!

Балалар тагы кычкырып еглыйлар.

Кәримә *(кычкырып)*. Ля илаһе илла Аллаһе! *(Һәммәсе авыз эченнән әйтәләр. Бераздан соң.)* Ошбу укыган тәһлилләреңезнең савабын мәрхүм Хәйрулла Хисаметдин угылының рухына багышладыңызмы? *(Һәммәсе кычкырып еглый.)* Багышладыңызмы?

Барысы да яшь эченнән: «Багышладык»,— диләр, бар да кул күтәреләр. Бераздан Галимә чабып керә, боларны күрмәенчә.

---

*Күй* — авыл.

*Җами* — мәчет.

*Чәшмә* — чишмә.

*Чок* — бик.

*Япарды* — хәзерли иде.

*Вәрирди* — бирә иде.

*Сахур гәлдекдә давул чаларларды* — сәхәр вакытында барабан кагалар иде.

Г а л и м ә *(каты тавыш белән)*. Абызтай, теге каһәр падишаһны төшергәннәр, ди. Мөселманга җиңеллек буладыр, ди. Бөтен халык мәйданга җыелган! Тизрәк!

Һәммәсе тиз генә йөзләрен сөртеп торалар. Бар да аптырауда. Разыя тәрәзәне ача, урамнан «Яшәсен хөррият!» дигән тавышлар ишетелә.

К ә р и м ә. Алай булса, сугыш та бетте. Исән-сау булганнар һәммәсе иленә кайтыр!

Ф а т и х. Безнең әти генә кайтмас! Безнең әти генә кайтмас!

Ш а к и р ә. Ләгънәт төшкән, үзе дә дөмекте, әтине генә үтертте...

Ш ә ү к ә т. Бәнем дә бабам — гәләҗәк! Күй гидәҗәгем, мәктәбә гидәҗәгем, забит олачагым!

Ә с и р *(килеп керә, авызы ерылган, үзенә күрсәтеп)*. Мажар! *(Балаларга күрсәтеп.)* Мажар! Мажар!

Р а з ы я. Әйдәгез, һәммәгез!

Өстләренә киялэр, урамнан зур тавышлар ишетелә. «Яшәсен хөррият! Яшәсен милләт!»

Шул тавышлар эчендә п ә р д ә т ө ш ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй. Бер елдан соң. Пәрдә ачылганда сәхнә буш. Бераздан хатын доктор Г ө л с е м, аның артыннан Р а з ы я чыга. Разыя башын ак яулык белән бәйләгән. Өстенә зур бер шәл салган. Ябыккан, картайган, йөткерә.

Г ө л с е м. Бернәрсә юк, абызтай, катырак суык алдыргансыз, бер- ике көн тышка чыкмагыз инде.

Р а з ы я. Ничек чыкмыйсың? Бердәнбер кызым иде, инде ике ай була — бер хәбәр юк, күңел тынмый шул!

Г ө л с е м. Бернәрсә дә юктыр, менә хаты да килер, хәбәре дә булыр.

Р а з ы я *(йөткереп)*. Авызыңа бал да май. Әле менә бөтен гәзитә шул Кырымдагы бәлшәвик сугышы белән тулган. Мөфти хәзрәт кебек мөфтине кылыч белән турап диңгезгә ташлагач, ул безнекеләр нишләгәндер инде?

Г ө л с е м. Юк, берни дә юктыр. Әнә шул даруны иртә бер, кич бер эч. Ләкин кара, абызтай, суык тидермә!

Р а з ы я. Элгәре мәтрүшкә кайнатып ак бал белә эчсәң, кул белә алган кебек була иде, хәзер балы кайда да, мәтрүшкәсе кайда?!

Г ө л с е м. Күңелең ни теләсә, шуны аша, ни теләсә, шуны эч, ләкин сак бул, суык тидермә! Бераз өшәнеп киткәнсең, абызтай, күбрәк кайгырдың ахрысы?

Р а з ы я. Шулай булды шул! Минем язмышым шундый булды... Артка әйләнеп карасам, бер шатлыклы көн юк! Мин туйны да еглап иттем, җеназаны да еглап күтәрдем...

Г ө л с е м. Менә инде тынычлап торырсың. Парахут төшкәч, бик матур иттереп Уфа тирәсенә кымызга барырсың, азрак һава алыштырырга кирәк, абызтай!

Р а з ы я. Шулайдыр шул! Кырымнан нинди хәбәр була бит, мин бит тол тормышны татыган. Алай-болай кияүне үтермәсеннәр дә, кызым да үзем кебек булмасын дип шикләнәм...

Г ө л с е м. Юк, берни юк, хуш, абызтай.

Р а з ы я. Хуш, алай булса, зәгъфран белә «Аятелкөрси» яздырып эчәргә ярыймы?

Гөлсем *(чыга-чыга)*. Бик ярый, бик ярый, хуш!

Р а з ы я *(акрын гына йөри, тәрәзәгә бара)*. Менә шуннан хәзер кызым килеп керер кебек була... Ерак йирнең шунысы авыр шул! Шәүкәт угылым, син андамы?

Ш ә ү к ә т теге бүлмәдән: «Монда, монда!»— дип кычкыра да бераздан килеп чыга.

Ш ә ү к ә т. Йомышың бармы?

Р а з ы я. Юк, йомышым юк, әле ялгыз кебек булып киттем дә, чакырдым *(башыннан сыйпап)*. Сабак укыймсың?

Ш ә ү к ә т. Әйе, иртәгә бер мәктәптә төрекчә җырлыймыз, син барамсың, ханым?

Р а з ы я. Юк, угылым, күрмисеңме, авырып торам. Әнә кызымнан да хәбәр юк! Анда да — Кырымда бик күп мөселманны урыс кискән, ди. Куркып торам... Сездәге кебек кискән, суйган, тураган, ди *(тагы сөеп)*. Бар, угылым, укы сабагыңны! Кич белә, минем кызым белә кияү сәламәт булсын, дип, дога кыл, җәме!

Ш ә ү к ә т. Җә!

Разыя күзен сөртә, үзе йөткерә, Шәүкәт югала.

Р а з ы я *(ялгыз)*. Әллә ни күңелдә тынычлык бетте! Бу, дим, Хәйрулла абзый күңеленнән рәнҗеп үлдеме икән әллә дим? Шул үлгәннән бирле бөтенләй дәртем качты... Әллә нинди бер пәриме, шайтанмы, дошманмы басар кебек... Гел куркып торам. Шәүкәт!

Ш ә ү к ә т *(теге бүлмәдән)*. Нәрсә, ханым?

Р а з ы я. Сезнең хәлфәләр, монда да бөлшәвик мөселманны кисәр, дип сөйләмиләрме?

Шәүкәт. Юк, ханым, юк!

Разыя. «Юк» диген, «юк» булсын! Кырымда да булмаган булса, бик шәп була иде, ә?!

Галимә килеп керә. Өсте-башы тишенмәгән.

Галимә. Ник караңгыда утырасың, абызтай?

Разыя. Караңгы төштемени? Мин белмәдем дә! *(Галимә ут кабыза.)* Минә күңелле булып китте!

Галимә *(җентекләп карап)*. Дуктыр хәзер киләм дигән иде, килдеме?

Разыя. Килде. Йә, ни булдн?

Галимә. Ни булды? Боларның бит җәбәлә ягы юк! Анда барсаң, тегеннән кәгазь китер, ди. Монда барсаң, аннан, ди. Йөри торгач: «Син Шурага бар»,— диделәр. Шурасына киттем. Инде халык, инде халык! Безнең туташ вакытында безгә йөри торган бөтен яшь-җилкенчәк анда икән! Әле теге сучы Камалның угылы да анда шура булган булып утыра. Бардым. «Абызтай,— дидем,— туташның хәбәрен белә алмаенча бик борчыла. Көн дә телеграм җибәрәмез, берсенә дә җавап юк, хәбәр белешеп бир»,— дидем. Олугланып кына: «Ярый, карармыз»,— ди. Хәзрәтләр кебек утырган! «Карармыз түгел, җавап ал да бир! Атаңны абызтай бик күп ашатты, оныттыңмыни?»— дидем. Шуннан, теге, туташ вакытында йөри торган Әхмәт килеп чыкты. «Нишләп йөрисең, Галимә?»— ди. «Нишләп йөрим, элгәре туташ вакытында көн дә килеп сыйлана идеңез, самавыр куя-куя кулларым ярылап бетә иде, инде эзеңез юк,— дидем,— минә абызтай бик борчыла, туташтан ике айдан бирле хәбәр юк, телеграмга да җавап юк, шуңардан җавап алып бир»,— дидем. «Алай икән, дөрест, дөрест»,— диде дә китте. Тагы берсен алып килде. Сөйләштеләр дә: «Мин,— ди,— иртәгә тугры чыбык белән сөйләшермен»,— ди. «Тугры белән сөйләрсеңме, кәкре беләнме — безгә хәбәр генә бир! — дидем. «Ярый, ярый, иртәгә үзем хәбәр итәрмен»,— диде. Шуннан сине исәнме дип сорады. «Исән дә, бик борчыла»,— дидем. «Үзем керермен, үзем хәбәр итәрмен»,— диде.

Разыя. Бәлки берәр хәбәр килмәсме? Күңелем бик курка, Галимә!

Галимә. Синең күңелең курыкмаган вакыты

---

*Тишенмәгән* — чишенмәгән.

*Җәбәлә ягы* — мәгънә ягы, рәте.

булмады инде! Син туйдан да куркасың, җеназадан да куркасың... Син куркып туган инде...

Р а з ы я. Һәрвакыт күңел куркуым тугры чыкты шул!

Г а л и м ә. Чыкты, ди, чыкмыймы соң?! Дару алырга кушмадымы?

Р а з ы я. Юк, шул барларны гына эчәргә кушты.

Г а л и м ә. Аннан теге безнең әчтрине күрдем, яхшы атка менгән, әфичәр кебек киенгән, үзе көлә: «Мин,— ди,— бәлшәвик булдым»,— ди. Каһәр генә икән! Кайтып җиткәндә әле урамда аксак Шакирларның асравына очрадым: «Кая барасың, Мәрфуга?» — дидем. «Мин бит,— ди,— кияүгә чыктым,— ди. «Кемгә?»— дидем. «Әчтригә!»— ди. «Соң ул мөселманмы?»— дидем. «Түгел»,— ди. «Мөселман булмагач, ярамый ласа»,— дидем.«Хәзер ярый, яңа закун чыккан»,— ди. Исем китте, абызтай!

Р а з ы я. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!

Г а л и м ә *(чыга башлап)*. Ахыр заман инде, самавыр куйыйммы?

Р а з ы я. Куй, эчәрмез. Чәйгә берәр кеше чакырмыйсыңмы?

Г а л и м ә. Кемне?

Р а з ы я. Юк, әле тегеләй әйтәм, чит кеше белән кайгы онытылыр иде, дим. *(Галимә чыгып китә. Разыя ялгыз кала. Бераздан.)* Шәүкәт! Син андамы?

Ш ә ү к ә т *(теге бүлмәдән)*. Монда, ханым!

Р а з ы я. Син, сабакларың беткәч, миңа тәрилкә яздырырга барырсың, җәме?!

Ш ә ү к ә т. Ярый, ярый.

Р а з ы я *(тәрәзәгә барып карап)*. Тагы көн үтте, тагы кич булды. Тагы хәбәр килмәде... *(Калтырана, озын гына йөткерә дә өстәл янына утыра.)* Ул инде исән-сау булсалар, үзләре дә бер хатмы, телеграммы җибәрми булмаслар иде... Үтергәннәрдер шул! Шәүкәт, сездә мөселманнарны үтергәндә телеграм бар идеме?

Ш ә ү к ә т. Аңламадым, ханым!

Р а з ы я. Шулайдыр шул. Укы, сабагыңны укы! Аллага тапшырдым... *(Ишекне кагалар.)* Әллә ишек693 кактылар? Әллә телеграм килдеме? *(Тагы кагалар.)* Галимә! Галимә! Ишек шакыйлар, телеграм килде булырга кирәк, ач әле.

Галимә сызганган җиңен төшерә-төшерә үтеп китә.

Р а з ы я. Хәерле хәбәр генә була күрсен! *(Ишек ачыла, солдат киемендә бер кеше килеп керә, Галимә артында басып тора.)* Йә, ни? Ни кирәк?

Кеше *(госманлы төрек шивәсе беләнрәк сөйли)*. Ханым әфәнде, гаеп итмә, сездә бер төрек баласы юкмы?

Шәүкәт *(теге бүлмәдән кычкыра)*. Бабам, бабам! *(Чабып чыгып атасының муенына асылына.)* Бабам, бабам!

Кеше. Угылым, угылым! *(Бик озак кочаклашып торалар.)*

Разыя. Менә бәхетле кешеләр кавыштылар! Минем кызымнан һаман хәбәр юк !

Фәрит. Ханым әфәнде, гафу итәсез, угылымны ике ел югалткан идем...

Шәүкәт. Ханым әфәнде, бабам! Ханым әфәнде, бабам!

Разыя. Узыңыз... Утырыңыз!

Фәрит. Тәшәккүр идәрем... *(Узып утыра. Шәукәтне итәгенә утырта.)* Баламны тәрбияңез өчен бик рәхмәт!

Разыя. Берни түгел, бер ятим мөселман баласы дип тәрбия иттем. Әллә ни карый алмадым, гаеп итмәңез! *(Галимәгә)*. Самавырыңны керт! Кунак туңгандыр.

Галимә. Хәзер, хәзер...

Разыя *(Фәриткә)*. Исемеңез ничек, кунак?

Фәрит. Фәрит, ханым!

Разыя. Менә исән-сау кеше бервакыт кавыша. Минем элгәре ирем үлде, тол калдым... Кызым бар иде, аны тәрбия иттем. Ул кияүгә чыкты, Кырымга китте, ялгыз калдым... Бер күршемез бар иде, яхшы күрше иде. Солдат булды, үлде... Мәрхүм булды!.. *(Йөткерә.)* Әле инде кызымны югалттым, ике ай булды, хәбәр юк. Бәлшәвик Кырымда мөселманны бик тураган, ди. Үлмәделәрме икән дип бик куркам.

Фәрит. Юк, ханым әфәнде, юк, иншалла, сагларды...

Разыя. Шулай булсын инде! *(Галимә самавыр кертә, чәй сала.)* Әфәнде, өстеңезне салыңыз!

Фәрит *(аптырабрак тора.)* Минем өст-баш бик шәп түгел, ханым, беләсез, без әсирлектә... Ике елдан бирле Русиянең бер очыннан икенче очына сөрелдем. Әле бәлшәвик чыккач кына качтым, гаиләмне эзләргә дип качтым. Сибириядә идем. Бөтен шәһәрдә сораша-белешә монда кадәр ике ай килдем. Казанда төрек балалары күп дигәч, монда килдем. *(Киемен сала, өсте-башы бик сәләмә.)* Мин бераз кулымны юар идем, ханым!

---

*Тәшәккүр идәрем* — рәхмәт.

Разыя *(Галимәгә)* Шунда гына тас белә су бир!

Галимә комган, тас, сабын бирә, Шәүкәт сөлге тотып тора.

Фәрит *(кулын юа-юа).* Казанда өч көн эзләдем. Берничә йортка киттем, минем угылым улмады. *(Шәүкәтне сөеп.)* Ул монда икән!

Галимә чәй ясый, Фәрит утыра.

Разыя. Ашаңыз, арыгансыз! Чәйгә ияләштеңезме инде?

Фәрит. Инде һәммәсенә ияләштем.

Разыя. Татарча бик яхшы сөйлисез!

Фәрит. Лагерьда татар гәзитләре генә укып тордык. *(Фәрит ашый-эчә башлый.)* Угылым зурайган. Бик яхшы тәрбия иткәнсез, ханым, рәхмәт! *(Үзе зур кабып ашый.)* Әле минем бүген ашаганым юк иде... Гаеп итмәңез, ханым!

Разыя. Бик ашаңыз, бик... Галимә, берәр кайнар нәрсәң юкмы?

Галимә. Хәзер аш өлгерә!

Фәрит. Мәшәкатьләнмәңез! Мәшәкатьләнмәңез! Без ачлы-туклы торырга өйрәнгән...

Шәүкәт. Бабам, сакалың юкды?

Фәрит. Иштә өсди, өсди, угылым! Ихтияр улдым. *(Разыяга.)* Инде угылымны таптым. Хатынымны табарга гына калды. Ул кайда сөреләә торгандыр, мискин кадин!

Шәүкәт. Анаммы, бабам? Анам олди... Анамны олдердиләр, бабам!

Фәрит *(катып китеп).* Олдердиләр? Олдердиләр... Кемнәр олдердиләр? Юк, олдермәдиләр... Мин аларның сәгадәтләре өчен ике сәнә мөхарәбә япдым... Юк...

Шәүкәт. Казак гәлди.. Әрмәни гәлди. Төфәк патлады. Җами төтенлә тулды. Анам йирә дүшди. Канә бугылды. «Шәүкәт!»— диде. Әлеми сыкты. Алла!— диди,олди... олди... бабам!

Фәрит *(сикереп торып башын тотып).* Тагыниләр күрәчәгем бар икән? *(Еглый.)*

---

*Тас* — таз, ләгән.
*Юкды* — юк иде.
*Иштә* — хәзер.
*Ихтияр улдым* — шулай теләдем.
*Мөхарәбә яптым* — сугыштым.
*Төфәк патлады* — мылтык шартлады.
*Әлеми сыкты* — кулымны кысты.

Разыя *(бераздан Фәрит янына килеп)*. Сабыр ит, әфәнде! Тәкъдир шулайдыр... Урыны оҗмахта булсын! Урыны оҗмахта булсын!

Фәрит *(күзен сөртеп)*. Ханым әфәнде, күңелле улып гаскәргә киттем, тукыз ай даимән мөхарәбәдә үлдым.. Дүрт дәфга яраландым. Әҗәлен янында тордым. Йөземи бер мәртәбә чытмадым. Бу хәсрәтне күрермен дип уйламаган идем... Аһ, Заһидә мискин, Заһидә! Йирә дүшди. Канә бугылды.«Алла!»— диди. Җан тәслим этди... Биз дә мөхарәбә япдык. Ләкин кәлисәгә кидүп дә кадинлари суймадык! *(Еглый)*.

Разыя *(чәйне биреп)*. Эч, әфәнде! Бераз күңелең басылыр!

Фәрит *(берәр йота да)*. Ханым әфәнде, гафу ит! Чәйнең дә тәме бетте. Тормышның да тәме, таты качты. Мөхарәбәдән соң гаиләм белә бергә яшәргә дип өмет итә идем... *(Тик тора, Шәүкәт тә күзен сөртә. Озын гына пауза.)* Нурия нә улды?

Шәүкәт. Нурия анамын әлендә иде. Әлендә иде...

Фәрит. Соңра нә улды?

Шәүкәт. Даһа казак гәлди. Даһа әрмәни гәлди. Даһа төфәк патлады. Нурия дә канә бугылды. Төтен бетди. Бән анамны үпдем. Нурияи ала чыкдым. Боз кеби суыкди, о, бабам, суыкди... Казак гәлди. Бәни алдыгитди... *(Фәрит тешләрен шыкырдата.)*

Фәрит. Мин шул хәбәрләрне ишетер өчен авылдан-авылга ике ай җәяү килдеммени? Ни өчен җәрәхәт өстенә җәрәхәт ачасың. *(Аяк өстендә калтыранып, калтыранып еглый.)*

Разыя *(торып, янына барып)*. Әфәнде, әфәнде, сабыр ит, язмыш шулай булгандыр... Син күрәсене башкалар күрмәс бит! Менә, әлхәмдүлиллаһ, алма кебек угылың бар! Үзең әле яшь. Яңадан оя корырсың! Яңадан тормыш башларсың, менә, тәһарәт ал да, хатының рухына бер һәүел намазы укы!

Фәрит. Дугру, ханым, дугру. *(Шәүкәткә.)* Угылым, су вармы?

Галимә. Бар, бар!

---

*Күңелле улып* — ирекле булып.
*Дәфга* — тапкыр, мәртәбә.
*Әҗәлен янында* — әҗәлнең янында.
*Канә бугылды* — канга батты
*Кәлисәгә кидүп* — чиркәүгә кереп.
*Кадинлари* — хатыннарны.
*Даһа* — тагын.
*Дугру* — дөрес.

Фәрит белән Шәүкәт чыгып китәләр.

Р а з ы я. Галимә! Кияүнең иске киемнәре бар иде, шуның берсен керт әле, өсте-башы бик беткән, бирәр күлмәк-ыштан да бир! *(Галимә чыгып китә.)* Бу дөнья! Шатлыгы да, кайгысы да бергә йөри. Кызымнан һаман хәбәр юк!

Г а л и м ә *(киемнәр күтәреп керә)*. Шулармы?

Р а з ы я. Шулар, шулар!

Г а л и м ә. Шәүкәт, Шәүкәт!

Ш ә ү к ә т *(еракта)*. Нәрсә?

Г а л и м ә. Монда кер әле!

Ш ә ү к ә т керә.

Р а з ы я. Атаңа шул киемнәрне бир, кисен! *(Шәүкәт күтәреп алып чыгып китә. Галимә дә чыга. Ялгыз, тәрәзәгә барып карый.)* Тыш караңгы! Өметсез... Кызымнан хәбәр юк. Тугры чыбыгы белә дә хәбәр юк. Кәкресе белән дә юк. Аллага тапшырдым!

Башка киемнәрдән Ф ә р и т, Ш ә ү к ә т килеп керәләр.

Р а з ы я. Менә шулай! Бик һәйбәт булган! *(Намазлык биреп.)* Менә кыйбламыз шунда! *(Фәрит намазлыкка тезләнеп утыра. Шәүкәткә)* Атаң янына тезлән! Ул дога кылыр, без «Амин» диермез!

Һәммәсе кул күтәрә, Разыя йөткерә, сирәк-сирәк кенә «Амин, амин», ди. Галимә, чәй урынын алып, аш урыны хәзерли. Дога кылалар.

Р а з ы я. Менә шулай. Коръән укыгач, күңел тынычлап китә ул! Әнә Шәүкәт атасын күреп ничек сөенде!

Ф ә р и т. Рәхмәт, ханым, сезгә! Балама да ана булгансыз. Үземә дә ана булдыңыз...

Р а з ы я. Мин тол хатын булып гомер иттем. Кайгының ачысын беләм. Кулымнан ни килсә, шуны эшләргә хәзер! Сез бит безнең рәхәтемез өчен дип кан түккәнсез. Безнең тынычлык өчен дип иленеңездән-көнеңездән читтә булгансыз. Алла әҗерен бирсен!

Г а л и м ә *(аш салып керә)*. Утырышыңыз!

Р а з ы я. Яңез, әфәнде, утырыңыз! *(Утыралар.)* Бу ашка да хәбәр булмады! *(Сискәнеп киткән кебек була.)*

Г а л и м ә. Нәрсә бар?

Р а з ы я. Капка төбенә чана туктаган кебек булды. Бар әле, кара әле!

Галимә. Синең күзеңә күренә, колагыңа ишетелә башлады инде.

Разыя *(тәрәзәгә барып карый)*. Бернәрсә күренми. Күзгә төртсәң, күренмәс! Галимә, бар әле, чык әле!

Галимә. Юк ла. Бернәрсә юк!

Фәрит. Мин чыгыйм.

Разыя. Юк, юк!

Галимә чыга башлый, ишекне ачуга ишектән аяк тавышы ишетелә, Галимә ишекне ачып җибәрә. Солдат шинеленнән, кулына баласын күтәргән Бану килеп керә. Керүе белә анасының муенына барып асылына.

Бану. Әнием, бәгырем, рәнҗеттем үзеңне! Әнием, бәгырем, рәнҗеттем... Әнием, бәгырем, бәхил бул! Валлаһи, сине рәнҗетәм дип уйламадым! *(Кычкырып еглый, икесе дә еглыйлар, соңра аерылалар. Бану Фәритне дә, Шәүкәтне дә күрми.Икесе ике якта еглап торалар.)*

Разыя. Күрсәт угылымны! *(Бану китереп анасына күрсәтә.)*

Бану. Бик туңды. Инде авырмаса ярар иде.

Разыя *(баланы алып)*. Угылым! *(Тагы әллә нәрсә әйтергә тели, әйтә алмый... Ахырдан.)* Кияү кая? Кая ул, кызым?

Бану. Әйтмә, әни, әйтмә, әни! Аттылар... Янымнан алып чыктылар да, дивар буена китерделәр дә аттылар... Чыгып та өлгерә алмадым! *(Акырып еглый.)*

Разыя. Аттылар? Аттылар? Ни дип аттылар? *(Урыныннан калка, тотына-тотына көчкә утыра, йөткерә.)*

Бану *(яшь эченнән)*. Белмим, әни, белмим, ачма җәрәхәтемне! Сугыш булды. Бәлшәвик җиңде. Безнең гаскәр тауга качты. Бәкер, мин гаскәр түгел, дип, китмәде. Әйттем, китмәде, һәр йирдә тентү ясадылар. Безгә дә килделәр. Берни тапмадылар. Бәкергә: «Киен!» — диделәр. «Кая алып барасыз?»— дидем. «Милициягә»,— диде. «Ярый»,— дидем. Шул вакыт угылым егларга тотынды. Шуны туктата-туктата соңгарак калдым. Кая алып баралар икән дип чыктым. Ишектән чыгуга «дөрст» иткән тавыш ишетелде. «Дөбер» итеп егылды. Мин дә котым чыгып егылдым. Шуннан ни булды, белмим... Җеназасына да тора алмадым. Ике атна саташып яттым. Аннан менә аякка басу белән, ялган солдат паспорты белән, монда чыктым. Өч атна юлда йончыдым. Кырык тентеделәр. *(Кычкырып еглый.)* Әнием, рәнҗемә, синең күңел сыкравың төште. Яшьлек. Белмәдем. Бу әни ничек ялгыз торыр икән дип күңелемә дә кертмәдем... Менә Бәкерне аткач кына синең хәлеңне аңладым! *(Икесе дә еглыйлар.)*

Фәрит. Сабыр итеңез, ханым... Сабыр итеңез!

Бану *(борылып карап)*. Әни, бу кем?

Шәүкәт. Бәнем бабам. *(Фәрит башын ия.)*

Бану. Син кем соң?

Разыя. Бездә торды, адашкан бер төрек баласы. Бу минем кызым, әфәнде, бердәнбер кызым. Киявен үтергәннәр.

Бану. Әллә кай төше Бәкер кебек булып китте...

Разыя *(акрын гына)*. Мин аңарга кияүнең киемнәрен кигезгән идем.

Галимә. Йә, утырыңыз инде, аш суына!

Бану. Бу көнне дә күререм бар икән! Әни, сине күрмичә үләрмен дип тордым.

Разыя. Мин дә бик борчылдым! *(Үзе йөткерә.)*

Бану *(курыккан тавыш белән)*, Әни, ник йөткерәсең?

Разыя. Суык алдырдым, кызым, суык... Яңез, утырышыңыз!

Бану солдат киемнәрен салып ташлый. Утырышалар.

Разыя *(Фәриткә)*. Менә хәзер һәммәмез тигез, һәммәмезнең кайгысы берсенекеннән-берсенеке ким түгел.

Бану. Әфәнденең исеме ничек?

Фәрит. Фәрит!

Бану. Фәрит әфәнде газиз угылын тапкан, без газиземезне югалтканмыз!

Фәрит. Мин дә, ханым әфәнде, газизләремне югалттым. Мин дә хәзер генә хатыным һәм кызым үлтерелгәнен ишеттем...

Разыя. Монда кайгысыз кеше шул бала гына! *(Тимергә күрсәтеп.)* Кара әле, кызым, көлеп ята!

Фәрит. Безнең хәсрәтләремез шуларга бәхет юлы ачсын инде!

Разыя. Шулай, шулай.

Бану. Фәрит әфәнде төрекме?

Фәрит. Әйе, әйе.

Бану. Сез бераз кырымчарак сөйлисез!

Фәрит. Татарча берлә төрекчә катышты. Иштә буйлә улды.

Разыя *(калтырап)*. Галимә, тунымны китер әле, туңып киттем...

Бану. Ни булды, әни?

Разыя. Берни түгел! *(Калтырана.)* Шулай менә туңып китәм, аннан тирләтә...

---

*Буйлә* — болай.

Бану. Әнием, бәгырем!

Галимә тун китерә, Разыя тун кия.

Разыя. Даруымны китер! *(Галимә дару китерә, Бану салып бирә.)*

Фәрит. Ханым әфәндене дуктырга күрсәтергә кирәк!

Разыя *(калтыранып)*. Бүген генә булды. Суык алдыргансың, ди. Язга кымызга бар, ди.

Бану. Кымызга бар, ди? *(Разыя йөткерә. Аптырап.)* Кымызга, ди?

Фәрит. Бернәрсә түгел, үтәр китәр...

Бану. Шулаймы, Фәрит әфәнде? Шулай булсын!

Маһруй чабып керә.

Маһруй. Нишләп торасыз? Бәлшәвик матросы килгән, ди. Татар бәлшәвикләре юл күрсәткәннәр, ди. Безнең халык аларны үтергәннәр, ди. Бәлшәвик белә сугыш башлана, ди. Шулай, ди. Шурадан: «Тәрәзәләреңезне капланыз!»— дип әйтеп йөриләр. Тәрәзәләрне капланыз, тәрәзәләрнең капкачын капланыз... Тиз булыныз! *(Үзе югала. Бар да катып калалар.)*

Бану. Уттан чыктым, утка кердем...

Разыя *(калтыранып)*. Күңелем курка иде. Тегендәге канга туймадылар, инде монда килделәр... Инде безне кисәчәкләр! *(Һәммәсе калтырана.)*

Фәрит. Ханым әфәнделәр! *(Үзенә күрсәтеп.)* Мин — намуслы төрек гаскәре, милләтем өчен бу кадәр сугыш иттем, милләтем угрына гаиләмне корбан иттем. Бүген мин монда, шул ике тол хатын, ике ятим баланың саклануы минем муенымда — минем муенымда милли бурычым! Курыкманыз! *(Кесәсеннән табанчасын чыгарып.)* Тәндә җаным бар вакытта бу ишектән дошман аяк атлый алмаячак...

Разыя, Бану. Рәхмәт, Фәрит әфәнде, рәхмәт!

Шәүкәт. Бабам, бән дә сәнинлә!

Бану. Мин дә сезнең белә!

Разыя. Барымыз да... Барымыз да бергә!

Фәрит. Һәммәмез бергә, һәммәмез бергә бу гаиләнең намусын саклаячакмыз, киләчәктә шул ятимнәр рәхәт яшәсен өчен җанымызны фида итәчәкмез! *(Угылын үбә. Бану баласын сөя.)*

---

*Милләтем угрына* — милләтем хакына.
*Табанча* — револьвер, наган.
*Сәнинлә* — синең белән.

Разыя. Иманнарыңызны әйтегез!

Галимә ишекләрне бикли. Балталар алып килә. Тышта мылтык шартлавы, пулемет тавышы, кычкырган, бакырган тавышлар ишетелә.

Пәрдә төшә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй. Дүрт-биш ай вакыт үткән. Өйдә җиһаз, тәрәзәләрдә пәрдәләр юк. Ишек шторы алынган. Көзгеләр, сәгатьләр юк. Бөтен дивар буп-буш. Бөтен бүлмә буш. Пәрдә ачылганда күрше бүлмәдә тавышлар ишетелә. Әллә нинди хатыннар көлмәкләре, мендәр кочаклап хатыннар ягыннан берничә солдат килеп керә. Әйберләрне уртага ыргыталар.

Берсе. Китерегез барысын да! Авыру булып яткан була... Буржуй!

Берничә кызыл солдат. Тиз атла, әллә мылтык түтәсенең тәмен беләсең киләме? Атла!

Диварга тотына-тотына гына Разыя чыга. Үзе калтырый. Бөкрәйгән. Өстенә искергән камзул кигән, шәл салган. Аның артыннан Бану чыга.

Комиссар *(утырган көенчә Разыяга)*. Кая акчаң, әйт?! *(Разыя йөткерә)*. Кая акчаң? *(Кызыл солдатлар һәммәсе дә табанчаларын ачып тотканнар. Бер солдат табанчасын маңлаена таба китереп.)* Акчаң кая?

Разыя. Юк минем акчам. Мин бер тол хатын. Юк минем акчам...

Бер солдат. Юк! *(Табанча китереп.)* Буржуйка! Мин күрсәтермен юкны!

Разыя калтырана, егылыр-егылмас кына аяк өстендә тора.

Бану *(артыннан)*. Оялыгыз, ичмасам, бик батыр булган икәнсез! Үләргә яткан бер карчыкны җиндегезме? *(Алга таба чыга башлап.)* Утыр, әни!

Бер кызыл солдат Бануны кулыннан тотып бәреп җибәрә.

Солдат. Буржуй, кан эчүче!

Солдат табанча түтәсе берлә суга, Бану диварга барып бәрелә. Теге яктан тагы берничә солдат әйберләр күтәреп керәләр.

Комиссар. Акчаң кая?
Разыя. Сиңа акча бик кирәкмени? Син алай тол хатыннарны талап рәхәт күрермен дип уйлыйсыңмыни? *(Үзе йөткерә.)* Күсәк кебек башыгыз белә хатыннар талап йөрергә оялыгыз!

Бер солдат. Тик тор, буржуй, тик тор! Авызыңны җимерермен!

Разыя. Җимер, балакаем... Алла иманымны юлдаш итсен!

Бану. Әни, утыр! Әни, утыр! *(Комиссарга.)* Ничек оялмыйсың аягына баса алмый торган бер карчыкны шулкадәр җәберләргә! Синең азрак оятың бармы?

Комиссар. Монда синнән сабак алырга килмәгәннәр! Акчаңыз каялыгын әйтсәңез, котыласыз!

Бер солдат. Бусы чибәр генә. *(Бануны тотмакчы була, Бану бәреп җибәрә.)*

Разыя *(ачы тавыш белә кычкыра)*. Оятсыз, тик тор! *(Комиссарга.)* Ул нинди оятсызлык? Кая сезнең оятыңыз, кая сезнең законыңыз?

Комиссар *(көлә)*. Закон... Ә закон?! Бик күп безнең канны эчтеңез!

Разыя. Без сезнең канны эчтекме? Мин ничек синең каныңны эчә алам, ди. Мин — бер тол карт хатын. Син — бер таза ир. Син — бер урыс. Мин — бер мөселман. Ничек мин синең каныңны эчә алам, ди. Таласы әйберләреңне таладың, бар, юлында бул!

Хатын-кыз ягыннан бер солдат бер бутылка динатурат күтәреп керә.

Солдат. Ура, ура! Нәрсә таптым... Буржуй яшереп куйган. *(Кулында чынаягы, барысына да салып бирә. Эчәләр, үзе исерә төшкән. Көлеп.)* Эһе-эһе. Буржуйлар, курыктыңызмы? *(Разыя борынына табанчасын итеп.)* Иснә, тәмлеме? Буржуйка!

Бер солдат. Нәрсә монда вакыт әрәм итәргә? Стенага сөяргә дә...

Комиссар. Менә сезгә биш минут вакыт, шул биш минутта акчаңыз, алтын-көмешеңез кайдалыкны әйтсәңез, котыласыз, әйтмәсәңез, диварга сөйимез дә, атамыз да үтерәмез...

Разыя. Биш минут вакытыңызны әрәм итмәңез! Юк безнең акчамыз!

Солдатлар икесен дә дивар янына сөйиләр. Разыя берлә Бану кулга-кул тотышкан көенчә дивар буенда торалар.

Комиссар. Ике минутыңыз үтте! *(Солдатлар шарт-шорт табанчаларына ядрәләр куялар.)* Бер минут гомереңез калды, әйтеңез яхшылык белә...

Бану. Безнең әйтәсемез әйткән!

Комиссар. Актык сүз: кая акчаңыз?

Разыя. Мин падишаһмы акча өләшергә?

Комиссар. Яңез, өйрәтеңез шуларны!

Теге исерек солдат бутылкасыннан динатур салып Разыяның авызына итә.

Солдат. Эч, буржуйка, батыррак булырсың! *(Бар да кычкырып көлә, солдатлар табанчаларын тугрылап торалар.)*

Разыя. Ля илаһе илла Аллаһе... Йә, ат, ни карап торасың?!

Шәүкәт килеп керә, солдатларны күргәч, аларга ябыша.

Шәүкәт. Олдермә, ханым әфәндене оүлдермә! *(Әле берсенә, әле берсенә бара.)* Олдермә! *(Еглый.)* Руслар анами олдердиләр, ханым әфәндене олдерәчәкләр... Бабам, бабам, сән нәрәдә? Бабам, дошман вар! *(Чыгып китә.)*

Шул арада Галимә чабып керә.

Галимә *(солдатларны күреп)*. Оятсызлар, караклар! *(Әле бер солдатны бәреп йибәрә, әле берсен. Исерек солдат кул салырга тели. Аны бәреп ега.)* Тик тор, оятсыз!

Комиссар. Тик тор! Син дә диварга сөяләсең киләме? *(Разыяга.)* Әйтәмсез?

Разыя. Безнең сиңа әйтәсе сүземез юк!

Комиссар. Пли!

Шарт-шорт табанча атыла. Өй төтен белә тула. Шәүкәт кереп кычкырып еглый. «Бабам!»— дип кычкыра. Хатыннар һаман баскан көенчә торалар. Төтен ачылыр-ачылмас Разыя һушсыз булып егыла. Авызыннан кан килә.

Бану. Әнием, бәгырем, әнием, бәгырем! *(Анасына ыргытыла, солдатлар табанчаларын тыгалар.)*

Комиссар. Әле куркытыр өчен генә, юри генә аттык... Өч көнгә сезгә миһләт, өч көндә әйтмәсәңез, чынлап атып үтерәмез! Әйдәңез, иптәшләр!

Солдатлар әйберләрне ала башлыйлар, бер солдат егылган Разыяның шәлен тартып ала.

Галимә. Бирдем, ди. Сезгә дип күлмәк теккән идем, ди. *(Тартыша, әйберләрне ала, солдатлар бәреп җибәрәләр, теге исерек солдат кычкырып көлә.)*

Комиссар. Киттек, иптәшләр! *(Бар да чыгып китәләр.)*

Шәүкәт. Бабам, бабам! *(Кычкырып чыгып китә.)*

Галимә белә Бану Разыяны күтәреп кәнәфигә яткыралар.

Бану. Су китер, Галимә! *(Үзе еглый.)* Әллә инде

---

*Нәрәдә* — кайда.
*Миһләт* — кичектереп тору.

үлә... Әллә инде үлә! Авызыннан никадәр кан китте... Кара, ичмасам, ядрә тигәнме, әллә һушы гына киткәнме?

Галимә *(су биреп)*. Авызына су сал! «Бисмилла» әйтеп сал! Бер җирендә дә кан юк... Тимәгән!

Икесе дә Разыя янында маташа. Шәүкәт, Шәүкәт артыннан Фәрит килеп керә. Фәрит табанчасын ачып тоткан, боларны гына күреп, аптырап кала.

Фәрит. Каялар?

Бану. Акрын, Фәрит әфәнде! Әни һушсыз булды, әллә инде үлә үк? *(Аңарга карап.)* Син дә шул табанчаны күтәрмә инде, ичмасам! Болай кот очканымыз җитмәгән, ди...

Фәрит *(табанчасын яшереп)*. Гафу итәсез, ханым... Мин теге дошманнар бар дип ачып кердем!

Фәрит тә килеп Разыя янына туктый, бар да карап торалар. Озын пауза.

Разыя *(акрын гына)*. Су бирегез, су, җаным көя... Ля илаһе илла... Аллаһе! *(Галимә су бирә, Разыя эчә. Тагы пауза. Разыя күзен ачып, Фәритне күреп.)* Син дә мондамыни? Һичбер нәрсәдән курыкмадым, Фәрит кенә кайтып кермәсен дип котым очты. Алла саклады. Ашыйсы ризыкымыз бар икән әле. Син булсаң, кызу кеше, чыдый алмаячак идең. Бәхетемез икән! Барымызны да атып үтерәчәкләр иде!

Фәрит. Сезне шулкадәр авыр хәлгә төшергәнче минем үлүем артык иде!

Бану. Шул гына калды, ди! Җеназа җитмәгән ди инде бу йортта!

Разыя. Юк, сез яшьләр яшәгез инде! Үлем кизүе минеке. Шәүкәт, кил, балам, утыр! *(Шәүкәт утыра.)*

Галимә. Каһәр сукканнар! Бөтен дөньямны актарып бетергәннәр! Чәч такмама булыр дип өч бөтен саклый идем, урлаганнар кяферләр...

Разыя. Хәерлегә булсын, Галимә! Тәрәзәләрне корыгыз да... бик эчәсем килә!

Галимә, Фәрит, Бану төрле нәрсәләр белә тәрәзәләрне корырга тотыналар.

Бану *(Фәриткә)*. Инде урамга ут күренерлек түгелме? Тагы боларның керосины бар икән дип кермәсеннәр, дим!

Фәрит. Яхшы булды! *(Шәүкәткә.)* Угылым, бар, урамга чыгып кара, тәрәзәләрдән якты күренмиме? *(Шәүкәт чыгып китә.)*

Разыя. Бу каторга тормыш кайчан бетәр икән?!

Фәрит. Төрек гаскәре Бакуны забыт иткән, ди. Аннан Әстерханга киләчәкләр, ди. Аннан, иншалла, Казан да озак түгел!

Разыя. Алла бирсен иде!

Шәүкәт *(кереп)*. Якты күренми.

Разыя. Чәеңез булдымы? Бик көйдем...

Бану. Булды, әни, булды.

Галимә самовыр кертә, чәй салалар.

Разыя. Галимә! Кара яктан гына кереп хәзрәтне чакыр әле. «Абыстай бик авырып ята... Васыятьнамә яздырыр идем, керсен лә!»— дип әйтте диген.

Галимә. Нинди васыятьнамә ул? Ул бит теге каһәрләр генә куркытты!

Бану. Әни, кирәкми, кирәкми!

Разыя *(йөткерә)*. Ул васыятьнамә булгач, күңел тынычланып китә! *(Йөткерә, Бану чәй ясап бирә.)*

Фәрит. Ханым, васыятьнамә яздырудан зарар юк. Ләкин иртәгә көндез имам әфәндене чакырсаңыз ничек булыр?

Разыя. Бүген... *(йөткерә)*. Хәзер... Шул мәлгуннең мылтыгы тигән булса, хәзер бит үлек була идем... Минем соңгы теләгемне кем белә иде... *(Шәүкәткә.)* Бар, угылым, син дә Галимә белән барыш!

Шәүкәт белә Галимә чыгалар. Разыя чәйне ала да, кулы бик калтырый. Бану чәен күтәреп эчерә. Фәрит катыбрак тора.

Разыя. Тыныч үсмәдем... Рәхәт яшәмәдем... Тыныч үлә дә алмыйм! *(Йөткерә. Бануга кулын салып.)* Синең өчен борчылам, кызым, синең өчен... Хәзерге хәлдә, бу яшь балаң белән... тол көенчә ничек дөнья кичерерсең!

Бану. Әйтмә, әни, әйтмә! Кирәкми... *(итәгенә ятып еглый)*. Син үлмисең... Әни, син үлмисең!

Разыя. Һәр эш Алладан. Тәкъдирдә ни язылгандыр. Кымызга да бара алмадым... Юлы киселде шул!

Фәрит. Иншалла, ханым, терелерсез!

Разыя. Үзем өчен түгел... Шул чуалышлар беткәнче генә, кызым өчен генә аз гына торыр идем дә бит! Язган ризыгың бетсә! *(Йөткерә, Фәрит әллә ни әйтмәкче була, әйтә алмый.)* Кызым! Үлсәм-нитсәм, үзе чыкмаса, Галимәне чыгарма! Азрак базынган да, нишлисең инде, үзе тугры, алты ел сынадым, үзе чыкмаса *(йөткерә)*. Үзе теләсә, барлыгың булса, туй итеп кияүгә бир...

---

*Забыт иткән* — басып алган.

*(Фәриткә.)* Утыр! Чәй эч! Сиңа да ияләштек... Безгә — тол хатыннарга бик зур иптәш булдың. Рәхмәт...

Фәрит *(утырып)*. Мин, ханым әфәнде, кулымнан ни килсә, сезнең гаиләңез өчен эшләргә хәзер! Менә тереләңез дә, сөйләшермез, кунушырмыз... әле..

Галимә белән Шәүкәт килеп керәләр, Галимәнең кулында бер төен.

Галимә. Менә хәзрәтнең чалма-чапаны. Аны трибуналга чакырганнар, ди. Азрак посыбрак торадыр, ди. «Тавыш-тын чыгармаңыз!»— диде. Мин ишек ачарга төшәм.

Бану шәл ябына, Галимә чыгып китә, бераздан ишектән солдат шинеленнән хәзрәт, аның артыннан Галимә керә.

Хәзрәт. Әссәламе галәйкем, курыкмаңыз! Мин бәлшәвик түгел. Әле, беләсез, дөнья шулай икән инде...

Фәрит. Вәгаләйкем әссәлам! Боерыңыз, хәзрәт.

Хәзрәт солдат шинелен салып ташлый, чапанын кия, чалма чалырга тотына.

Хәзрәт. Тегендә сезнең төрекләрнең хәленә сөенеп тора идек. Менә монда ниләр булды!

Фәрит. Шулай, хәзрәт, шулай...

Разыя. Утырыңыз, хәзрәт... Гаеп итмәңез, тел ачтым... *(Хәзрәт утыра.)* Менә хәлем авыррак... Васыятьнамә яздырыйм дим, хәзрәт!

Хәзрәт. Әйе... Безнең остазымыз мәрхүм дамелла Фәхри: «Мин утыз дүрт яшемдә васыятьнамәмне яздырып куйдым»,— дия иде. Васыятьнамәдән зарар юк. Кәгазь-караңыз бармы? *(Бану кәгазь-кара бирә.)*

Фәрит. Хәзрәт, чәй ясыйммы?

Хәзрәт. Чын чәйме? Алма яфрагы гынамы?

Разыя. Чын чәй, хәзрәт, чын чәй...

Хәзрәт. Алайса, берәрне ясаңыз. Без бит инде Милли идарә тарафында. Без бәлшәвикне танымыймыз, без моны Алланың йибәргән бәласе генә дип карыймыз. Шуның өчен һәрнәрсәне үз милли теләгемез, үз шәригатемез буенча эшлимез... Сез дә, абызтай, шуны тели торгандырсыз бит?

Разыя. Шулай, шулай... Менә, хәзрәт, мин әйтим, сез үзеңез белеп языңыз! *(Хәзрәт васыятьнамәнең башын яза. Бар да тик торалар.)* Күрше фатирдагы Хәйрулла абзыйның балалары үсеп җиткәнче шул фатирларында бушлай торсыннар... Әйеме, кызым...

---

*Кунушырмыз* — киңәшербез.

Аның угылы ир, кызы хатын булганча фатир хакы алма! *(Бану башын ия.)* Үземнең авылда атамнан калган алма багчамыз бар иде, аны бөлшәвик алды инде алуын да. Алай да бер кайтыр әле... Шул багча авылымызның кызлар мәктәбе өчен булсын! Балык базары чатындагы кибет уртаклата Шәүкәт белә кечкенә угылым Тимергә булсын! *(Хәзрәт яза.)* Хәтфә тышлы тунын, үзем кия торган калфагым, килен чактагы чатма күлмәгем, каенанам күрендереп биргән алкам, ике беләзегем, ике йөзегем, ал өстенә чәчәкләндереп каеган җефәк камзулым Галимәгә булсын... Кызым, болар кайда, беләмсең?

Бану *(еглаган тавыш белә).* Беләм, әни! *(Галимә дә еглый.)*

Разыя. Иремнән калган хәтфә палас үземезнең мәсҗедкә җәелсен! Вә башка бөтен мал-милкем кызыма...

Хәзрәт. Шулай, шулай! *(Яза. Пауза.)* Менә тәмам. Моңарга инде шаһитлар кирәк иде!

Разыя. Фәрит, син кул куй!

Фәрит. Баш өсте! *(Хәзрәттән каләмен алып кул куя.)*

Разыя. Кызым, син дә куй! *(Бану үзе еглый, үзе кул куя. Колагыннан алкасын алып хәзрәткә бирә).* Хәзрәт, менә рәхим итеп шул алкаларны алыңыз! Кызыңызга булыр, үзем кигән алкалар. Инде миңа кирәкми. Яшьләргә булсын...

Хәзрәт *(алып).* Рәхмәт, абыстай!

Разыя. Алай-болай үлеп китсәм, хәзрәт, китап әйткәнчә җыеңыз инде. Кызым яшь, хәзрәт. Кешем юк...

Хәзрәт. Мин мәгъзүр инде, абыстай, беләсез бит, качыбрак торам. Мөәззингә әйтермен инде... Әле балачага бар диген... Җан газиз. Посыбрак торам. Мине бит: «Мәдрәсәдә дин дәресе укытмый ярамый»,— дип әйткән дип, трибуналга биргәннәр *(торып).* Хушыңыз! «Хөррият, хөррият»,— дип көттек, менә ни булды! Хуш! *(Фәрит озата чыга.)*

Разыя. Бик туңам, кызым! *(Өстенә китереп ябалар. Пауза. Фәрит керә. Галимә белә Бану — Разыя янында, Фәрит — читтәрәк. Разыя йөткерергә тотына, буылып йөткерә. Кан какыра.)* Эһе-эһе, азрак җиңеләеп киттем. Сүндермә самавырыңны! Гөжләп торсын! Әтиеңез мәрхүм гөжләп тормаган самавырдан чәй эчми иде. Мәрхүм булды. Хәйрулла абзый да үлде... Әйе... Кияүне дә үтерделәр! *(Бану чәй бирә, Разыя, азрак эчеп, Галимәгә.)* Гали-

---

*Мәгъзүр* — берәр сәбәп белән бер эшне эшли алмаучы.

мә, бик күп хезмәт иттең, рәхмәт! Мин үлгәч туташны ташлама... Ул яшь кеше, кызар да, тиргәр дә, аны калдырып чыкма! Дөньялар тынычланганча тор, җәме!

Галимә *(еглап)*. Җә, җә!

Разыя *(Шәукәткә)*. Син зур булырсың, әтиең кебек олуг булырсың... Мине онытма! Бер әби бар иде, дип, дога кыл, Коръән укы, җәме!

Шәукәт. Җә... җә... *(пауза)*.

Разыя. Кызым... кызым! *(Йөткерергә тотына, озын йөткерә, яулыгына кан какыра... Карылган тавыш белә.)* Кызым *(бишектәге балага күрсәтеп)* бала хакы дип торма! Кешесе тугры килсә, кияүгә чык... Кияүгә чык... Бер кайгыны ялгыз күтәргәнче икәү бүлешерсез... Бала хакы дип үз хакыңны корбан итмә! Кияүгә чык! *(Бану кычкырып еглый, Фәрит торып әллә нәрсә әйтмәкче була, Разыя йөткерергә тотына. Разыя Бануның башын кулы белән сыйпый.)* Фәрит! *(Фәрит аякка калкып Разыя янына килә.)*

Фәрит. Нәрсә, ханым?

Разыя. Сиңа бик күп, бик күп сүз әйтмәкче идем... *(йөткерә.)* Шулай булды инде...

Фәрит. Боерыңыз, ханым! *(Пауза.)*

Разыя. Сине бик күп сынадым. Син яхшы кеше, яхшы кеше. Кызым... Кызым!

Бану. Нәрсә, әни?

Разыя. Фәрит, дим, яхшы кеше... Әйеме, кызым?

Бану. Әйе...

Разыя. Әйе... әйе... Сиңа бик күп сүз әйтер идем... Син әле кан кардәш, син әле дин кардәш булсаң да, ят кеше... *(йөткерә.)* Әйеме, кызым?

Бану. Әйе, әни!

Разыя. Әйе, диген... әйе... Чит кеше шул... Әйте, ят кеше... Син, мөмкин булса, иленне, күйеңне бик сагынмаган булсаң... *(йөткерә)*, мин үлгәч тә Шәукәтне алып китмә... Ул Бануга иптәш булыр, өйдә ир заты булыр... Әйеме, кызым?

Бану. Әйе, әни!

Разыя. Әйе, үзең теләсәң нишлә, сиңа ышанычым камил... әйеме, кызым?!

Бану. Әйе...

Фәрит. Ханым әфәнде! Тагы бик күп еллар яшәңез! Мин һәрвакыт сезнең хезмәткә хәзер! Бану ханымга да шулай...

Разыя. Шулай, шулай... Кызым ялгыз кала... Кияү үлде... Агасы, энесе булмады... Үзе тол... Үзе ятим... Үзе ялгыз...

Ф ә р и т. Рөхсәт бирегез, мин угылым белә шушы кечкенә бүлмәдә торыйм?!

Р а з ы я. Теләсәң, бик рөхсәт... Зур бүлмәдә теләсәң, зур бүлмәдә тор... Әйеме, кызым?!

Б а н у. Әйе...

Ф ә р и т. Йөз ел яшәгез, ханым әфәнде! Ләкин мин Бану ханым үзе кит димәсә, аны ялгыз калдырмаячакмын!

Б а н у. Ник әйтим, ник әйтмим... Әни дә үлсә, син дә китсәң, мин нишлим, ди....

Ф ә р и т. Мин әмерегезгә мөнтәзыйр!

Р а з ы я. Сине, Фәрит, угылым кебек күрәсем килә иде, гомерем вафа итмәде...

Ф ә р и т. Рөхсәт ит, ханым, угылың улыйм!

Р а з ы я. Ни дисең, Фәрит?

Ф ә р и т. Рөхсәт ит, ханым, угылың улыйм!

Р а з ы я. Шулай, шулай... *(Бану күзен ачып аптырап тора, Пауза.)* Әйеме, кызым?

Б а н у. Әйе, әни!

Р а з ы я. Фәрит, шулаймы? Аңладыңмы?

Ф ә р и т. Шулай, ханым, шулай. Бану ханым разый булса, сез рөхсәт бирсәгез, үземне-үзем мәсгуд санар идем! *(Бану башын ия.)*

Р а з ы я. Кызым, кызым... Кара миңа, кызым! *(Бану күзен күтәреп карый, башын саллый, Фәрит Разыяның кулын үбә.)* Миннән фатиха! Алла изге гомер, мәңгелек бәхет бирсен! Сиңа ышанычым зур, Фәрит! Кызымны күз нурым кебек сакладым... Яңез, бер дога *(кулын күтәрә)*. Алла тормышыгызны моң кылмасын, тормышыгыз минеке кебек китек булмасын, гомерегез әрәмгә үтмәсен! Бер-берегезгә хыянәт итмәгез! Кызым, алдыңа килгән нигъмәтнең кадерен бел *(йөткерә)*, иреңнең гаебен күрмә, сукыр бул! Дөнья булгач, була... сукыр бул! Фәрит! *(Бишеккә күрсәтеп.)* Бу гөнаһсыз баланың атасы милләте юлында шәһит киткән, аны боектырма! Ата бул...

Ф ә р и т. Баш өсте, ханым... Баш өсте!

Р а з ы я. Кызым! *(Шәукәткә күрсәтеп.)* Бу ятимнең анасы халкы өчен корбан булган, аңарга үгилек итмә, анасы кебек йомшак, җылы бул! *(Бану башын ия. Разыя йөткерә, буылып-буылып йөткерә, кан какыра. Һәммәсе*

---

*Мөнтәзыйр* — буйсынучы, әзер торучы.
*Вафа шимәде* — мөмкинлек бирмәде.
*Мәсгуд* — бәхетле.
*Саллый* — селки.

*карап торалар. Бердән Разыя сикереп аягүрә тора. Каты тавыш белә.)* Галимә! Ука чәчәкле күлмәгемне, чатма камзулымны китер! Ал хәтфә калфагымны, ефәк шәлемне китер, энҗе-мәрҗәннәремне китер! Тиз бул, китер... Исле майны онытма! Мин туй итәм... Мин кызымны бирәм. Бердәнбер кызымны күңелем теләгән кешегә бирәм... Тиз китер... Бик күп кайгылы яшәдем. Бик күп күз яшемне түктем. Бүген мин шат, бүген мин шат... Бүген мин туй итәм... Зур туй итәм... Як лампаларны! Бөтен өй яктырсын! Як һәммәсен! Бөтен кардәш-кабиләне чакыр! «Туй итәмез!»— диген. Туй! Бар да килсен, бар да безнең туйны күрсен! Шатлыклы туйны күрсен!

Бану *(янына килеп).* Әни, әни... әнием! *(Разыя ишетми.)*

Разыя. Уенчылар килсен! Уенчылар һәммәсе уйнасын... һәммәсе җырласын! Бөтен дуст-иш сөенсен, көлсен! Бөтен дошман көенсен... егласын! Туй! Яңы тормыш. Туй! *(Урамда бик каты мылтык шартлавы ишетелә. Разыя бердән туктый.)* Үтерәләр, үтерәләр, бәлшәвикләр үтерәләр... *(дип бик каты кычкыра да, лап итеп егыла. Бану белән Фәрит тотарга өлгерә алмый калалар, ул җан бирә).*

Бану *(кулына ятып).* Үлде, үлде, әнием, бәгырем, бәхил бул!

Фәрит аптырап тора. Шәүкәт кычкырып еглый. Галимә катып кала. Ишектән Кәримә карчык иске киемнән һәм Маһруй күренәләр.

Икесе дә. Ни булды? Ни булды?!

Бану. Әни үлде... үлде...

Барысы да башларын иеп, тезләнеп, кулларын күтәреп дога кылалар. Урамда шатыр-шотыр ату тавышы куәтләнә.

Пәрдә төшә.